Мамадыш районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе “Көек-Ерыкса балалар бакчасы”

# Шәхес тәрбияләүдә милли -төбәк компонентының роле



*(Тәрбиячеләр өчен методик кулланма)*

Төзүчеләр: Варисова Илира Хатимовна
Шайхутдинова Мәдинә Ваккасовна

2021 ел

**Мамадыш районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе “Көек-Ерыкса балалар бакчасы”**

# Шәхес тәрбияләүдә милли-төбәк компонентының роле

**Төзүчеләр**
**Варисова Илира Хатимовна**
**Шайхутдинова Мәдинә Ваккасовна**

**Мамадыш районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе “Көек-Ерыкса балалар бакчасы”**

Рецензент:

Төзүчеләр: **Варисова Илира Хатимовна, Шайхутдинова Мәдинә Ваккасовна -** Көек-Ерыкса балалар бакчасының беренче квалификация категорияле тәрбиячеләре.

Бу методик кулланма туган якны өйрәнү, үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, аның кыйммәтле үрнәкләрен балаларга җиткерү, бүгенге көн үзгәрешләре белән дәвамчанлыкны күрә белү һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү эшен балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр, әти-әниләр, студентларга эшчәнлектә һәм эшчәнлектән тыш оештыруда ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

# Эчтәлек

Кереш......................................................................................................................5

Проект .Туган авылым.................................................................................................7

Көек-Ерыкса авылы тарихы......................................................................................11

Бакчабызның үткәне һәм киләчәге...........................................................................13

Авылым чишмәләре...................................................................................................

Авылым күлләре.........................................................................................................

Балаларыбыз иҗаты...................................................................................................

Туган ягыма мәхәббәтебез шигъри юлларда..........................................................

Авылдашларыбыз туган ягым матурлыгы турында................................................

Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече...................................................

Каурый-каурый каз канаты......................................................................................

Шушы яктан, шушы туфрактан без..........................................................................

Туган ягым — яшел бишек.......................................................................................

Минем туган авылым.................................................................................................

Авылым урамы...........................................................................................................

Убыриянең сихри аланында......................................................................................

Аваз салды дөньяга балам багалмам минем...........................................................

Яңгыр боткасы.............................................................................................................

Сабантуй бәйрәме.......................................................................................................

Куллланылган әдәбият................................................................................................

Кушымта: ...................................................................................................................

- рецензия..............................................................................................
- CD-R (диск)...........................................................................................

# Кереш

Туган өен белмәгән

Туган авылын белерме?

Туган авылын белмәгән

Туган илен белерме?

Туган авыл...Туган җир... Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр . Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты,нигезе урнашкан кадерле туган авылы бар . Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас,истә кала торган урыннары күп .Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары,җикән камыш белән капланган сазлыклар ,балыклы күлләр, куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре ,туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп туган туфракка мәхәббәт тәрбияли. Кая гына барсак та,туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алмаштыра алмый . Туган ягыбызның һәр сукмагы,һәр агачы ,һәр үләне,аның барча кешеләре күңелгә ифрат та якын. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр әттә-әннә дип әйтергә өйрәнгән вакыттан ук күңел түренә туган телебез аша кереп утырган ул кадерле урыннар.

Туган авылым -тау куенында,
Борма инеш буенда .
Кайларга гына барсам да,
Һаман минем уемда.

Кечкенәдән бала туган ягының табигатен,тирә-юньнең матурлыгын күрә, тоя белә.Шушы хисләрне вакытында күреп алып,дөрес юнәлештә үстерсәк балада туган яккакарата горурлану хисләре уяныр,аңарда туган якка тугрылыклы булып калу,аның байлыгын арттыру,аны матурлату хисе барлыкка килер. Шытып чыккан яшь үсенте сыман, нәниләребезгә якты кояш, "игелекле туфрак" кирәк.

Ананың төп бурычы туган телнең бай мөмкинлекләреннән файдаланып, бала күңеленә, сабый йөрәгенә матурлык, игелеклелек, инсафлык орлыклары чәчү. Шушы бай мирасыбызны кулланып, ана телен танып-белү, аның байлыкларын сөйләмдә куллана белсәк, ирекле, белемле, бар яктан сау-сәламәт, зыялы, тормышта үз урынын мөстәкыйль табарга сәләтле, үз халкының үткәнен белүче, аның белән горурланучы һәм киләчәктә аңа хезмәт итәргә әзер булган , үз-үзен тәрбияләп камил шәхес булырга омтылучы кешеләр үстерә алачакбыз.

Балаларны туган халкыбызның үткәне, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, гаилә шәҗәрәсе, йолалары һәм бүгенге тормыш белән танышу зарур. Төркемдә исә без гаилә шәҗәрәсен ясау эшен алып барабыз. Әлеге эш нәселнең абруе турында кайгырту, гаилә ядкарьләрен күз карасыдай саклау – тарихи үзан, халкыңа хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләүнең

бер юлы. Гаилә тарихы аша бала үзенең кемлеген, чыгышын, туган йортының үткәнең, халкының тарихын, килеп чыгышын аңларга мөмкинчелек таба.

Тәрбия бирү алымнарын халык педагогикасыннан , гаилә тәҗрибәсеннән, әби-бабайларның тәгълим-тәрбия бирү алымнары арасыннан эзләп табып,шул алымнарны эштә кулланудa , әти-әниләргә җиткерүдә эшлекле эш алып барабыз.

"Каурый-каурый каз канаты...", " Шушы яктан, шушы туфрактан без..." ,"Аваз салды дөньяга балам-багалмам минем...""Сабантуй", " Убыриянең сихри аланында", "Яңгыр боткасы", "Гаилә бәйрәмнәре" бик нәтиҗәле үтә.

Бакчабызда һәр балага матур итеп тектерелгән милли киемнәр бар, бәйрәмнәрдә балалар милли киемнәрдән чыгыш ясыйлар. Бу балаларны да, әти-әниләрне дә милли традициягә якынайта.

Тәрбиячеләр, әти-әниләр , балаларның уртак көче белән "Туган як тарихын өйрәнү" музее эшләп килә.

Шәхес тәрбияләүдә бакча, гаилә генә түгел, мохит тә нык йогынты ясый.Ак мунчалы каралты-куралар, ак яулыклы, алъяпкычлы әбиләр, кәләпүшле бабайларның урамнан узып китүләре, байтак гаиләләрдә балаларның әнә шундый әби-бабайлар белән бергә яшәүләре, авылыбыз өстендә азан тавышлары яңгыравы халкыбызның гореф-гадәтләрен күреп үсәргә мөмкинлек бирә.

Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәнендәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, гомумән, балаларда милли аң, уңай караш тәрбияләүдә милли-төбәк компоненты зур әһәмияткә ия.

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм кечесенә,

Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле

Туган ягы кирәк кешегә.

# Проект. Туган авылым

**Бурыч:** үз авылыңның тарихын, истәлекле урыннарын белү.

**Максат:**

Туган як,авыл турынлагы белемнәрне киңәйтү.Балаларны авыл тарихы,аның урнашу урыны белән таныштыру.Туган авылга хөрмәт тәрбияләү, матурлыкны күрә белергә,аның белән сокланырга күнектеру.Урам исемнәрен истә калдырырга ярдәм иту.Бәйләнешле сөйләм ,хәтер,уйлау сәләтен үстерү, сүз байлыгын арттыру.Патриотик хисләр формалаштыру.Авылның күренекле кешеләренә хөрмәт тәрбияләү. Халыкның гореф-гадәтләрен саклап калырга дигән төшенчә керту.Бердәм, бер төркем белән дус,тату уйнауларына ирешү.

**Проект тибы:** танып белү, сөйләм үсеше, нәфис - нәфасәти үсеш, социаль - коммуникатив үсеш, физик үсеш.

**Проектның дәвамлылыгы:** дүрт ел

**Фараз:** Әгәр дә тәрбия эшендә балаларга , туган илгә, туган авылга карата мәхәббәт тәрбияләүдә төрле чаралар үткәрелә икән, димәк, бу аларның патриотик хисләрен формалаштыруда зур роль уйнаячак.

**Эчтәлекнең төре:** Бала, тирә-як мохит, туган якның тарихи һәм сәнгать истәлекләре.

**Проектның этаплары.**

**1.Алдан башкарылган эш:**

Перспектив эш планы төзү, фотога төшү,проектны иллюстратив материаллар белән баету,ата-аналар өчен анкеталар үткәрү; методик китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре сайлау, проект турында әңгәмә оештыру.

Районның картасы белән таныштыру,аннан үзебезнең авылны табу. Балаларның әби-бабайлары,туганнары,дусларының кайсы районнарда яшәүләре белән кызыксыну.

Балалар бакчасын мәктәп, китапханә,мәдәният йорты белән тыгыз элемтәдә тотып, бергә хезмәттәшлек иту.

**2.Төп өлеш**

Авылның тарихы, истәлекле урыннары, халыкның һөнәрләре, гореф-гадәтләре турында шөгыльләр үткәрү, экскурсияләр оештыру.

Тарих укытучысы Руслан Миннефаилевич тарафыннан “Көек -Ерыкса авылының килеп чыгышы” турындагы чыгышын тыңлау.

Туган якның байлыгын, табигать матурлыгын күзәтү максаты белән авылның тирә-як басу-кырларына, чишмә - су буйларына , тауга сәяхәткә чыгу.

Әти-әниләр ярдәме белән “көзге табын-бай табын” ярминкәсе, “Авылымның уңган куллары” исемле күргәзмәләр оештыру.

Балалар белән күмәк хезмәт – авыл картасын төзү.

Әти-әниләр белән берлектә Һәр баланың өеннән бакчага кадәр булган юл-маршрутын төзү.

Консультацияләр оештыру,ата-аналар белән әңгәмәләр кору.

”Сез авылны беләсезме?” анкета уздыру.

Сюжетлы-рольле уеннар уйнау ”Гаилә”, “Мәктәп”, “Балалар бакчасы”, “Ватанны саклаучылар”.

Авылда үткәрелгән конкурсларда, концертларда, милли бәйрәмнәрдә катнашу; мәдәният йортынд балалар белән чыгыш ясау.

Авылда иҗат итүче Рәим Гобәй, Рәсимә Галиева белән очрашып, әдәби кичәләр үткәрү.

Авылыбыздан чыккан күренекле кешеләр: Илһам хәзрәт Миннегалиев,Талипова Гөлнәзирә, Гимранов Салават, Давытов Рамис, Гараев Зөфәрләр белән очрашу, әңгәмәләр үткәрү.

**Проектның актуальлеге.**

Туган як, туган почмак һәр кеше тормышында аерым бер зур,якын,кадерле урын алып тора. Үз авылыңны, аның тарихын, атаклы, дәрәҗәле шәхесләрен, халыкның гореф- гадәтләрен белү бик мөһим.

Кечкенәдән балалар аңларлык итеп туган ил, туган авыл турында сөйләп, тарихи вакыйгалар белән таныштырып ; аны яратырга, сокланырга, горурланырга өйрәтеп, авыл тормышы белән даими кызыксындырып торсак-балаларда әхлаки-патриотик тойгылар формалашыр; табигатькә, туган якка, татар халкының йолаларына, сәнгатенә карата мәхәббәт тәрбияләнер, бала туган илнең лаеклы гражданины булып үсәр, аларның кечкенә йөрәкләрендә туган илгә карата мәхәббәт очкыннары кабыныр.

**Проектта катнашучылар:** кечкенәләр, уртанчылар, зурлар , мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, бакчадагы тәрбиячеләр, ата-аналар.

## Проектның планы

| *Белем бирү өлкәләре* | *Эшләү алымы һәм формасы* |
|---|---|
| *Танып белү үсеше* | “Авылның истәлекле урыннары” на экскурсия . Файзә, Солтан, Комазан чишмәләренә ,инеш буйларына сәяхәт.Китпаханә, почта, фельшер акушерлык пунктына , мәчеткә, мәктәпкә максади сәяхәтләр оештыру. Инеш буйларыннан,чишмә тирәләреннән чүп җыю.<br>“Һөнәрләр” темасына рәсемнәр карау. Авыл урамнары, урман-кырларына,табигатенә багышланган “Минем авылым ” исемле презентация тәкъдим итү.Борынгы газеталар карау.Элеккеге фотолар аша хәзерге авылны чагыштыру.<br>“Туган якны өйрәнәбез” альбомы белән танышу. Авылдагы климат |

| | |
|---|---|
| | шартлары турында әңгәмә.Төрле хайваннар, үсемлекләр дөньясы, яшәү тирәлеге турында альбомнар булдыру.Экологик әкиятләр сәхнәләштерү.<br>Табигатьне саклау буенча төрле чаралар уздыру. Агачлар утырту, бакчаны чиста тоту, бакча тирәли субботниклар ясауда өлкәннәргә булышу. |
| ***Сөйләм үстерү*** | “Туган авылым –Көек Ерыкса”,”Авылым урамы” шөгыльләре. “Каурый-каурый каз канаты” , Яңгыр боткасы”,Аваз салды дөньяга балам-багалмам минем”,”Шушы яктан,шушы туфрактан без”, ”Сабантуй”,”- әти-әниләр, тәрбиячеләр өчен күңел ачу иртәләре.<br>“Авылым урамнары”.“Туган ягым-яшел бишек”-эшчәнлек ;<br>“Үсемлекләр дөньясы, кошлар,хайваннар турында табышмаклар кичәсе үткәрү.“Чукмар белән Тукмар” әкиятен сәхнәләштерү.<br>З. Туфайлова “Туган ил”.Р.Фәйзуллин “Безнең ил”<br>Г.Рәхим “Безнең тауда”.Г.Тукай “Туган авыл”<br>Г.Зәйнәшева “Туган авылым”. |
| ***Физик үсеш*** | **Сюжетлы-рольле уеннар:**<br>Даруханә.Янгын сүндерүчеләр.<br>Ватанны саклаучылар.Автобуста.<br>Балалар бакчасы.Гаилә.<br>Шифахәнәдә.<br>**Дидактик уеннар:**<br>Урман дусларын ата.Безнең урманда яшәүче.<br>Хайваннарны тап.Авылның урамын әйт.<br>Бу кайчан була?Кемгә ни кирәк?<br>Елгада ниләр яши?Сәяхәткә ниләр кирәк?<br>Рәссам нәрсәне бутаган? |
| ***Нәфасәти үсеш*** | **Рәсем**.<br>Минем авыл.Мин яшәгән йорт.<br>Көзге урман.Әкияти өйләр.<br>Безнең авыл машиналары.<br>Мин балалар бакчасыннан әти-әнием белән кайтам. |

| | |
|---|---|
| | Урам буенча баручы автобус.<br>**Кисеп ябыштыру**<br>Безнең урам өйләре.Авылдагы транспорт.<br>Урман аланында гөмбәләр үсә.<br>**Әвәләү**<br>Авылдагы биналар макеты.Тәрәзәле өйләр.<br>Күп катлы йортлар.Табигый материаллардан эшләнмәләр.Балалар рәсемнәреннән күргәзмәләр.<br>**Музыка**<br>"Туган авыл";"Дружат дети всей земли" (сл. В, Викторова, муз. Д.Львова-Компанейца)<br>«Улыбка»( муз В.Шаинского, сл. Пляцкова)<br>"Мин яратам сине,Татарстан! (Р. Рәкыйпов сүзл, Р. Андреев муз)<br>**Җырлы-биюле уеннар:**<br>Кәрия-Зәкәрия.Чума үрдәк,чума каз.<br>Челтәр элдем читәнгә.Миңлебай.Күрсәт әле,Габдулла. |
| ***Социаль-коммуникатив үсеш*** | Авылның мәртәбәле, мактаулы шәхесләре, ветераннары белән очрашу.<br>Иҗат итүче авылдашларыбыз Рәим Гобәй,Рәсимә Галиева белән әдәби кичәләр оештыру.<br>Авыл буенча сәяхәт. Китапханәгә бару.<br>Төркемдә "Туган як" почмагы, "Әбием сандыгы" милли музей булдыру. Авылыбыздан чыккан күренекле кешеләр: Илһам хәзрәт Миннегалиев, Талипова Гөлнәзирә, Гимранов Салават, Давытов Рамис, Гараев Зөфәрләр белән очрашу, әңгәмәләр үткәрү. |




## Көек-Ерыкса авылы тарихы

Көек-Ерыкса авылы көнбатыштан көнчыгышка таба агучы Комазан елгасы буена урнашкан. Көек орфографик термины Татарстан топонимиясендә чагылышы куе урманнар күп булган Казан арты территориясе өчен характерлы.Борынгы заманнарда  кешеләр куе урманнар арасына килеп утырганнар.Ачык урын ясап авыл нигезләү һәм чәчүлек җирләрне,кыр-басу барлыкка китерү өчен,урманны ут төртеп яндырганнар.Шушы ысул белән барлыкка китерелгән чәчүлек җирләрен Көек басу,Көек кыры,шул урыннарга утырган авылларны Көек дип атаганнар. Ә Ерыкса сүзенә килгәндә бу термин ерык+су сүзләреннән кушылып ясалган һәм тора-бара “Ерыкса” булып киткән, ягъни Көек-Ерыкса авылы шушы сүзләрдән кушылып ясалган. Авылның төньяк өлешендә,таулар,көнчыгыш ягында болыннар һәм Нократ елгасы ага (авылдан 8 км ераклыкта)коньякта калкулык һәм урманнар,көнбатышта шулай ук калкулыклар урнашкн. Көнчыгыш яктагы болынларда бик күп күлләр бар,шулардан иң зурлары Кәрәкә,Юкәле,Кешер,Киндер,Тирән күлләр.Комазан елгасының бер башы Комазан башы авылы янышнан (авыл исеме дә елга башыннан алынган) икенче тармагь Иске Комазан авылы арасында ике тармак бергә кушыла (Ерыкса,ерыксу) һәм елга авыл буенча

агыа Арпач күле аша Нократ елгасына барып тоташа. 1950 нче еллар ахырына хәтле су белән тегермән эшли иде (авылныңбер башында су ярдәме белән ындыр табагында ашлык сугу машинасы хәрәкәткә китерелә иде.1950 еллар ахырына кадәр Көек-Ерыкса авылында ГЭС эшләде, елга ике урыннан буыла иде һәм су буа булган урыннарда 5-7 м тирәнлектә җитә иде. 1930 елларда колхозлар төзелә башлагач безнең Көек-Ерыкса авылында “Марс” колхозы оеша.Бу ел була. Бу елда колхозга 42 хуҗалык керә.Беренче председатель-Мифтахов Сәйфетдин.Аны Гыйлҗметдин Сәйфетдинов алыштыра,соңрак Әюпов Гапсәләм.Бу елларда “Марс” таа 4 бригада була.Бригаданың 23 сыеры була.Беренче бригадир Хафизов Рәхимулла,ревкомиссия председате Садыйков Сәләхетдин булалар.

.Авылга беренче тракторлар кайту авыл кешеләре өчен бәйрәмгә әверелә.1932 елда “Марс” һәм “Вилком” колхозына 2 трактор кайта. “Марс” ка тракторны Сәхәбиев Мәҗлетдин ә “Вилком” га Корбангалиева Мәгъмүрә алып кайталар.Болар “Фордзок”маркалы тракторлар булалар.1930 елларда тракторларда Дәүлиев Хаҗи,Гәрәев Фатих,Аухадиева Шәмсенурлар эшлиләр.

1941 елда Бөек Ватан сугышы башлангач ике авылдан 345 ир-егет сугышка китәләр.Бөтен эш хатын-кызлар,картлар һәм балалар җилкәсенә кала.Сугышта 238 авылдан Ватан өчен тормышларын бирәләр.Исхаков һәм Бакыев Салихлар,Салахиев Фатих,Шәйдуллин Әбелхәсән,Газизуллин Газизҗан,Сагыйров Кадыйр һ.б. бик күп авылдашларыбыз орденнар һәм күп авылдашларыбыз орденнар һәм күп авылдашларыбыз орденнар һәм медальләр белән бүләкләнәләр.

Сугыш елларында “Марс” колхозы икегә аерыла.Көек-Ерыкса авылының югары очы “Марс”дип, ә түбән очы “Венера”дип атала башлый.Сугыштан сон “Марс”ның председателе Гыйльфанов Васыйл, ә “Венера” колхозына Миннебаев Хәнәфи була. 1946 елда игеннәрне беренче мәртәбә МТС тан китерелгән комбайн белән уралар.1946-50 нче елларда һәр га дан алынган уңыш 7-10 ц дан артмый.Көек-Ерыкса авылында сарык фермасы оештырыла.Биредә озак еллар буе Зарипова Кафия эшли.Ул 1938 елда авылдан беренче буларак район советына депутат булып сайланган була.

1956 елда 5 бүлмәле столовое һәм склады булган балалар бакчасы ачыла.Балалар бакчасы җәен эшли.Ә кышын бу бинаны 2 ел рәттән (1956-58 елларда) тирә-як авылларыннан трахома авыруыннан авыртучыларны дәвалыйлар.Ә 1964-80 елларда бу бинада медпункт һәм бала тудыру йортлары оештырыла,бина 1981 елда сүтелде.

1957 елда авыл радиолаштырды,радионың бер бүлмәсе файдаланылды.Шул ук елда клуб бинасы (элекке мәчет) ремонтланып үзгәртеп салынды.

1959 елда авыл библиотекасының яңа бинасы сафка басты,библиотека бу бинада авылны электрлаштыру башланды,төштән электростанция салынды,беренче электриклар Шакиров

Йосыф,Сафин Әхмәтгали,Сагыйров Кадыйр,Сәмигуллин Рәис, шул ук бинанаың икенче өлешендә йон тетү цехы эшли башлый.

1960 елда Көек-Ерыкса 7 еллык мәктәбе 8 еллык итеп үзгәртелде.Моңарчы директор булып эшләгән Хисамов Х.Б урынына Хабибуллин Н.Х. (Хабибуллин Н.Х. 1961 елда РОНО мөдире булып эшли башлый.)

Колхозда 1960 елда беренче үзйөрешле комбайн эшли башлый.1960 елның ноябрь аенда авылда Советлар Союзы Герое М.П Девятаев белән очрашу үткәрелде,ә декабрь аенда композитор Нәҗиб Җиһанов белән очрашу булды.Бу елларда композитор Арслан Батыршин (1961) язучылар Мирсәй Әмир (1962),Габделхәй Сабитов, Илдар Юзиевләр (1964)белән очрашулар оештырылды.

1964 елның ноябрь аенда “Дружба” колхозы оешуның 5 еллыгы билгеләп үтелде.Бәйрәм телевидениягә төшерелде,республика,район артистлары катнашында зур концерт күрсәтелде.

1969 елда авылга мәктәп салыну башлап җибәрү өчен проект оешмаларыннан специалистлар килделәр һәм 1970 елдан мәктәп төзелә башлады,мәктәп 1977 елда ачылды.1978 елдан балалар бакчасы, ә 1991 елдан бакчасының ике бинасы сафка басты.

1982 елда авылның Яна Культура йорты төзелеп бетте (шунда ук библиотека)

Авылда үзгәртеп кору елларына кадәр барлык хуҗалыклар да яңа йортлар төзеп керделәр, 10 нан артык ике квартиралы йорт төзелде.Хәзерге кыен елларда да төзелешләр дәвам итә.1996 елда авылның үзәк урамына асфальт түшәлде.

## Бакчабызның үткәне һәм киләчәге

Һич онытмыйк үткәннәрне

Чал тарихка кат-кат күз салыйк....

Россиядә балалар барлык халыкның дүрттән бер өлешен тәшкил итә.Алар илебезнең киләчәге.Шуңа да дәүләт һәм гаилә һәр баланың тормышы һәм үсеше өчен уңай шартлар булдыру өчен җаваплы.

Дәү әби-бабайларыбызның сөйләүләре буенча колхозлашу чорында авылыбызда зур эшләр вакытында балаларны шәхси өйләргә җыеп “ясле-бакча”лар ясаганнар.

Авылыбызның тарихыннан күренгәнчә,1950 елларда әле күп эшләр кул көче белән башкарылган.Ул чорларда күп балалы гаиләләр гадәти күренеш була.Һәр гаиләдә уртача 7-8 бала үсә.Мәсәлән, Яңа Комазан авылында Гараев Вәли һәм Рашидә апаларның, Көек – Ерыксадан Сафин Муллахан һәм Шәмсия апалар 11 әр бала үстерәләр.Ул вакытта һәр эшли алган кеше колхоз эшенә тартылган. Караучысы булмаган гаиләләр, тыныч күңел белән эшләсеннәр өчен,балаларны аерым өйләргә җыйганнар.1950-1951 нче елларда Сафин Ирек

пуҗымында, июль –август айларында балалар бакчасы оештырылуы билгеле.Балаларны карау әби-бабайларга йөкләнгән.Алар балаларны хезмәт аша тәрбияләгәннәр.Малайлар утын әзерләү,су кертү белән шөгыльләнсәләр,кызлар әбиләре белән җыештыру эшләре,кул эшләре, аш-су эшләренә өйрәнгәннәр. Әйтем, мәкальләр, такмаклар өйрәткәннәр. Зуррак балалар бишек җырлары,әкиятләр сөйләп кечкенәрәкләрен карарга булышканнар.Алар яшь буынга кешелеклелек сыйфатларын: намуслылык, шәфкатьлелек, инсафлылыкны васыять ,тәҗрибә хәзинәсе итеп тапшырганнар.

Еллар үткән саен балалар бакчасы ачу котылгысыз булып кала.1956 елның февраль аенда Көек-Ерыкса һәм Яңа Комазан авылы балалары өчен беренче проектланган балалар бакчасы төзелә. Бу эш колхоз көче белән башкарыла. Балалар бакчасы Мухаметшин Мөнир белән Гайни Саниясе өйләре арасында була.Ул табигатьнең иң матур җирендә тау итәгендә, инеш буенда урнашкан була. Балалар бакчасының дүрт бүлмәсе, верандасы, пешерү, юыну бүлмәләре була.Зур матур бакчасы балалар уеннары өчен бик уңайлы була.Җәй көне генә эшләгән, калган вакытларда төрле чаралар сайлаулар, җыелышлар үткәрү өчен кулланганнар. Бакча мөдире Ганиева Дөлшат апа сөйләве буенча, бакчада 25-30 балалы бер төркем эшләгән. Тәрбияче Тәүхитова Зәйтүнә, повар Әюпова Гайшә, завхоз –Мухаметшина Мәскүрә.

1960 нчы елларда кул хезмәте кимеп, техникалар кулланыла башлау сәбәпле, җәйге балалар бакчасы оештырылу туктатылган. Әлеге бина медпункт, роддом буларак хезмәт иткән.

1974 елда Көек-Ерыкса авылында агачтан яңа балалар бакчасы төзелә башлана.Ул Гараев Фәнилләр пуҗымында урнашкан була, һәм ул 1978 елда кулланышка тапшырыла. Балалар бакчасында ике төркем эшли, барлыгы 50 бала тәрбияләнә.1978-1980 елларда балалар бакчасын Ганиева Зөбәрҗәт җитәкли.1980 елдан Ахметшина Рәкия,1981-1985 елларда Сәйфетдинова Хәнүзә апалар эшли. Бу вакытта махсус урта белемле тәрбиячеләр,шәфкат туташы,музыка белгече эшлиләр. Тәрбия эше типовой программа буенча алып барыла. Балаларның иминлеген, сәламәтлеген саклау буенча төрле чаралар үткәрелә. Хәнүзә Мухаметдиновна җитәкчелегендә бакча хезмәткәрләре 31 бала белән Казан шәһәренә, бакча тарихында беренче тапкыр сәяхәткә баралар. Бу олы сәяхәтне оештыру җитәкченең,бакча хезмәткәрләренеңбердәм, зур җаваплылыкны бергә тоеп, кулга –кул тотынышып, дус- тату эшләүләрен ачык күрсәтә. Хәнүзә Мухаметдиновна җитәкләгән елларда бакча тормышында җитәкченең таләпчән, инициативалы, ярдәмчел булуы белән күп эш башкарыла.

1984 елның 1 январеннән балалар бакчасы Мамадыш районы мәгариф бүлеге карамагына тапшырыла.“Чебурашка” балалар бакчасы белән 1985-1991 елларда Шамсутдинова Миннур апа идарә итә. Миннур Накиповна бик көчле, тырыш, кайгыртучан җитәкче була. Һәрвакыт хезмәткәрләренә бик игътибарлы, итагатьле, кешелекле була. Балар бакчасында тәрбияләнүче балалар, тәрбиячеләр өчен елдан-ел уңай шартлар тудыруга көчен кызганмый.Ул үз янына үзе

шикелле үк хезмәткәрләр туплый. Алар: Хафизова Гөлбизә, Маннапова Рузия, Фахрутдинова Маһинур, Гарипова Рәмзия, Маннанова Мәйсүрә, Сафина Люцияләр.

Бу коллектив –тәрбияләнүчеләр, әти-әниләр тарафыннан зур хөрмәт белән искә алына.Алар бакча тормышында, мәктәптә, районда үткәрелгән күп кенә чараларда актив катнашканнар.

1991 елның 11 октябрендә Көек-Ерыкса авылында ике катлы зур, кирпеч, яңа бина ачыла.”Ләйсән” балалар бакчасытулы көченә кереп, җиһазландырып,барлык уңайлыкларны булдырып эшли башлавы яңа җитәкче Галеева Нурия Миннахметовнага йөкләнә.Балалар бакчасы 6 төркемгә, 110 балага исәпләнгән.Зур музыка залы, спорт залы, кухня, кер юу бүлмәләре эшли. Балалар бакчасында 37 кеше хезмәт куя.Һәр яшьтәге балалар үз төркемнәрендә тәрбияләнгәнлектән,балалар бакчасындаэшләү балалар өчен дә, тәрбиячеләр өчен дә бик уңайлы була. Балалар бакчасы авылыбызның һәр кешесе өчен “шатлык йортына” әверелә.

1992-1994 еллардавакытлыча бакча мөдире вазифаларын башкарган җитәкче Ямалеева Әлфия Юсуповна хезмәте зур хөрмәткә ия.Ул зәвыклы, зыялы, таләпчән, тәҗрибәле җитәкче буларак искә алына. Әлфия Юсуповнаэшләгән елларда җылыту ташкүмер ягудан электр белән җылытуга алыштырыла.

Балалар киму сәбәпле, 1994 елның 1 сентябреннән балалар бакчасы 3 төркемгә калдырыла. Югары белемле тәрбиячеләр Гафарова Рауза Ахкамовна, Варисова Илира Хатимовна, Шайхутдинова Мәдинә Ваккасовна, махсус урта белемле шәфкать туташы Миннегалеева Нурия Гуссамовна, соңрак Низамова Энҗе Миннулловна, пешекчеләр Иксанова Ильмира, Шайхутдинова Раушания, тәрбияче ярдәмчеләре Хабибуллина Нәсимә, Галлямова Синара, Шайхутдинова Рүзәнә, газ операторы Галеев Зиннур эшли. Бакчада мини музей, экологик бүлмә, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү бүлмәсе, фитобар эшли. Ян бакчада балалар өчен ел әйләнәсенә җитәрлек итеп яшелчәләр: бәрәңге,суган, чөгендер, кишер, кәбестә; алма, карлыган, чия үстерәбез.

2014 елның 1 сентябреннән балалар бакчасында тагы бер төркем кыскартылу сәбәпле, ике төркем эшли. Тәрбиячеләр, балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр авылда, районда, республика күләмендә үткәрелгән ярышларда катнашып призлы урыннар яулыйлар.

# Авылым чишмәләре

Тешне өшетерлек чишмәләр бар бездә,
Эчәм дә суларын тәнгә сихәт алам.
Дулкыннары җанга кагылып ага,
Чишмәләргә карап уйга калам.

Рафаил Газизов.

Авылыбызның нинди урында урнашуына игътибар икәнегез бармы?Бәлки, сез авыл очраклы рәвештә шундый урынга урнашкандыр дип уйлыйсыздыр. Юк, мондый матур урынны борынгы бабаларыбыз озак эзләгәннәр. Күрәсең, алар теләсә кайсы урында төпләнмәгән. Авыл булып утыру өчен якында гына урманы, болыны, инеше, салкын чишмә чыга торган калкулыклары булган урын кирәк булган.

Безнең Көек һәм Комазан авыллары нәкъ шундый урынга урнашканнар да. Салкын җилләрдән саклаучы калкулыкларга да, мул сулы чишмәләргә дә, болынлы күлләргә дә, урман һәм болыннарга да бай безнең авылыбыз.

Һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы , үз агымы, үз юлы бар. Бер ише шарлап ага, тавышы еракларга ишетелә, икенчеләре исә әкрен генә үзенә юл ала. Өченчеләре җир куеныннан кайнап, ургылып чыга Комазан тавының итәгеннән күпме чишмә чылтырап ага. Менә әкрен генә агучы Вакай чишмәсе. Ул таудан бераз читтәрәк агып чыга. Кайчандыр бу чишмәнең башы тау итәгендә булган. Еллар үтү белән ул күмелеп калган. Комташлар тәгәрәп төшеп шулай иткән аны. Чишмә янында гына Вакказ исемле кеше яшәгән. Бүгенге чишмәнең урынын ул чистарткан.

Моннан ничәмә-ничә гасырлар ничек аксалар, бүген дә шулай агып яталар алар. Комазан чишмәсе, Солтан чишмәсе, Тегермән чишмәсе, Ерак чишмә, Баллы чишмә шундыйлардан. Баллы чишмәне генә алыйк. Бүгенге көндә бу чишмә умарталык урнашкан урыннан агып ята. Бу исем аның җисеменә бик туры килә. Аның суы шулкадәр чиста ки, хәттә зәңгәрләнеп, кояш нурларында йылк-йылк килеп,ялтырап тора. Авылдан читтә урнашкан бу чишмәнең тарихы меңнәрчә елларга барып тоташа. Кайчандыр юу чишмә буенда кичке уеннар оештырылган, шат, моңлы җырлардан, дәртле биюләрдән чишмә тирәсе яңгырап торган.

Чишмәләрнең әһәмияте бик зур. Дөрес, хәзер авылда су үткәргеч торбалар салып, эчәр суны халыкка якынайттылар. Ләкин ул су инде чишмәләрнең табигый суын алыштыра алмый.

Әгәр кеше тәнендәге суның уннан бер өлеше генә кимесә дә, аның хәле начарлана, диләр, галимнәр. Менә бит суда нинди тылсымлы көч бар.

# Баллы чишмә

Баллы чишмә... Исемнәрең серле, күңелгә ятыш, үзеңә килешә һәм кем тарафыннан шулай яратып әйтелгәндер. Авылдан ерак түгел генә урнашкан умарталык эчендә тыныч кына агып яткангамы, әллә суыңнан кайнатылган чәй яңа гына алынган кәрәзле бал белән шулай татлы булгангамы, тик исемең синең минем өчен бик матур. Син хәзер генә шулай аз сулы, тыныч һәм тыйнак күренәсең. Хәтерлисеңдер, элегрәк яшьләрнең синең янга килеп гөрләтеп кичке

уеннар уйнаганын. Ә хәзер синең янга умартачыдан башка берәү дә килми, якын тирәңне чистартучы, юлларыңны ачып җибәрүче дә юк.

# Фаизә чишмәсе



Фаизә чишмәсе... Ә нишләп әле чишмәсе? Монда бит алар гаиләләре белән. Әйтерсең лә әнисе һәм чыр-чу килеп аның янында уен-көлкегә һәвәс кызлары уйнап йөри. Бер урыннан унлап чишмә әкрен генә ташлар арасыннан челтерәп чыгалар да, кояшта суларын миллион бөртек мәрҗәннәр җемелдәве белән күзләрне камаштырып ике-өч метр акканнан соң бергә кушылып юлларын дәвам итәләр. 2014 елда ремонт эшләре үткәрелгәннән соң, чишмәбез матураеп авылыбызга ямь өстәп тора.

# Солтан чишмәсе

Солтан чишмәсе известташлар арасыннан ургылып чыгучы,күп сулы чишмә.Көек-Ерыкса авылы халкы аның суын куллана. Элек бу чишмә кер чайкау өчен кулланылган.Бу чишмә заманында Солтан карт карап торганлыктан,аңа Солтан чишмәсе исеме бирелгән.2014 елда аның тактадан корылган өскормасын калайдан ясалганы белән яңартыды.Чишмә тагын да матурланды.



# Авылыбыз күлләре

Болыннарыбызда да сулыкларыбыз шактый безнең. Авылыбыз янәшәсендә генә Кәрәкә күле җәелеп ята. Ул 60 гектарга якын җирне били. Комазан чишмәсеннән аккан су инеш аша шушы күлгә кушыла. Башка җирләрдән аермалы буларак, Комазан чишмәсен һәм инешне бервакытта да кар-боз капламый. Чишмәдән пар бөркелеп тора. Кәрәкә күле тирәсендә берсеннән-берсе бәләкәйрәк күлләр тезелеп киткән. Кара күл, Зур Урсай һәм кече Урсай күлләре, "Урсай" сүзенең килеп чыгышы да кызыклы. Ул сүз " урыс ае " сүзеннән алынган дип сөйлиләр. Урысларның татарларны чукындырырга килүләре, бабаларыбызның чукынмас өчен бу күлләр янында качып ятулары белән бәйле бу күлләрнең исемнәре. Ә менә Бакмач күле, Түгәрәк күл, Ышна күле 50-60 елларда ук юкка чыкты, тирәсендәге агачларны кисү шундый хәлгә китерде аларны. Басудагы Торна күле дә юк инде хәзер. Авылдагы Сәхи күле, Биктимер күле, Миннехан күле, Рәхимҗан күле,Курмил күле дә бөтенләй юкка чыкканнар. Бакый күлендәге су бүгенге көндә аяк йөзеннән генә. Тирәнлеге белән аерылып торучы Тирән күлне, Кижер күлен,Киндер күлен, Камышлы күлен,Өзек күлен, Кәкре күлне күпләребез белә. Алар белән янәшә генә Минкә күле, Балыксыз күл, Корган җирлекле күле, Бәләкәй күл, Комлы күл, Чирмеш күле, Мүкле күл—барысы да үзенчә болыныбызга ямь биреп тора.

Әйе,безнең якларда эчә торган су запасы күп. Әле хәзергә су кытлыгы көтелми. Әмма кайбер илләрдә суны, самолет белән ташып, җан башына карап бүләләр. Дөньяның кайбер шәһәрләрендә гап-гади суны стаканлап саталар.

Бу хәлләр безне сагайтырга, табигатьнең бу кадәрле бүләгенә игътибарлы булырга кирәклекне искәртергә тиеш. Чөнки чишмәләре кибеп сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.

Чишмәләр һәм күлләр ни сәбәпле корый соң? Чишмә чыга торган урман яки агачлык киселеп бетә дә чишмә тирәсе, киемен салдырып алган кеше шикелле, ялангач кала. Бу урынны терлек- туар таптый,ул чүпләнә, пычрана. Шуннан соң чишмәнең корымый хәле калмый. Кайчандыр, төгәлрәк әйткәндә 50-60 елларда тулып утырган чиста сулы Комазан елгасы да чүп түгү урынына әйләнеп калган. Тирәнлеге 2-3 метрга җиткән елга бүген аяк йөзеннән яки тездән генә.Кызганычка каршы, су чыганакларыбызны күргәндә күңелле сөенеч урынына көенеч хисләре чолгап ала. Суларыбыз пычрана.

Табигатьтә һәр нәрсә үзара бәйләнештә. Җир—безнең туган йортыбыз. Елга-күлләргә ага торган пычрак, җиргә сибелгән сабынлы су, без урманда калдырган чүп-чар безнең гомуми йортыбыз булган табигатебезне пычрата. Әйе, без табигать тарафыннан бирелгән хәзинәләрнең кадерен белмибез шул. Әгәр табигатебезгә карата мөнәсәбәтебез киләчәктә дә

үзгәрешсез хәлдә кала икән, тиздән без балык тотучыларны да, көймәдә йөрүчеләрне дә, елга-күлләрдә су коенучыларны да очрата алмаячакбыз.

Бу юнәлештә республикабызда кискен һәм кичектергесез чаралар күрелмәсә, экологик афәт үзен озак көттермәс! Табигатебез мондый хәлдә булганда, алда безне ни көтәр...

Әйе, яшел яфраклар шаулап, болыннар, чирәмлекләр хуш ис бөркеп, чишмәләр чылтырап аккан урында яшәү нинди зур бәхет,нинди шатлык! Әйдәгез, чишмә һәм инешләр тирәсен һәрвакыт чистартып, тәртиптә тотыйк!



# Балаларыбыз иҗаты



Ильвина Х. 5 яшь



Айсылу С.6яшь



Алмаз Г. 5 яшь



Мәрьям З.6яшь

## Туган ягыма мәхәббәтебез шигъри юлларда...

### Көз килде.
**Бакчабызга көз килде,**
**Алмаларны кызартты.**
**Яфраклары саргая,**
**Ә балалар шатлана.**
**Илгиз С. 4 яшь**

### Минем авыл
**Матур минем авылым**
**Тавы бар,чишмәләре,**
**Урманнары җиләкле**
**Һәм балыклы күлләре.**
**Гүзәл Н. 5 яшь**

### Кыш
**Чыктык әле урамга**
**Таудан чана шуарга,**
**Рәхәтләнеп уйнадык**
**Үзебез ап-ак булдык.**
**Айрат Г. 6 яшь**

### Кыш килде
**Биек тауга бардым**
**Анда чана шудым,**
**Бөтен җирләр ап-ак**
**Матур безнең туган як.**
**Илназ Х. 5 яшь**

## Авылдашларыбыз туган ягым матурлыгы турында

**Читтән эзләмим бәхетне**
**Үз көем - җырым монда,**
**Әнкәем тире тамган җир**
**Җылынып учак миңа.**
**(Рәсимә Галиева)**

### Күңел ашыга.
**Кабат авылыма кайтып бару..**
**Кар астында бөтен тирә-як.**
**Җем-җем итә энҗе бөртекләре**
**Кар да яңа яуган, бигрәк ак.**

**Нарат егетләре колач җәеп**
**Тезелгәннәр яшел туннардан.**
**Каен кызлары да яннарында**
**Елышканнар, бераз туңганнар.**

**Әнә кар өстендә куян эзе,**
**Чаңгы юлы киткән сызылып.**
**Кар астыннан нидер тапкан бугай,**
**Козгын утыра чукып, зур булып.**
**(Шәйхетдинов Илшат )**


**Авылым**

**Бу якның чишмәсен, күлләрен**
**Кем күргән ,сокланган иң элек?**
**Кем генә булса да  авылымның**
**Урынын сайлаган бик белеп.**
**Урнашкан ул таулар кочагында**
**Тирә ягы болын, урманнар,**
**Мондый гүзәл авыл , йә әйтегез**
**Җир йөзендә тагын кайда бар.**
**Азга гына аерылсам да синнән**
**Моңсуланам күңелем борчыла.**
**Каләм алган саен кулларыма,**
**Чишмәләр күк ургып җыр чыга.**


**(Рәим гобәй)**

# Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече

## 2014-2015 уку елы




## 2015-2016 уку елы



**Кушымта 1**

# Каурый-каурый каз канаты

(Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә бәйрәм иртәсе)

**Максат.** Балалалрны үз милләтебез рухында тәрбияләү, халкыбызның гореф-гадәтләренә күнектерү.Онытылмас такмакларны ,уеннарны, өйрәтүне дәвам итү. Балаларда кечкенәдән үк әдәплелек, инсафлылык, мәрхәмәтлелек, ярдәмләшү хисләре һәм гадәтләре формалаштыру.Үзебезнең туган телебезгә мәхәббәт уяту.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, физик үсеш, социаль-коммуникатив, сәнгати үсеш.

**Талгын гына татар халык көе "Каз канаты" яңгырый. (Проекторда слайд.)**

-Хәерле көн кадерле кунаклар,балалар.

Каз өмәсе ул татар халкының көтеп ала торган иң күркәм йолаларының берсе. Авылларда элек-электән күп көч сорый торган эшләрне күмәкләшеп эшләгәннәр. Өмәдә барыннан да бигрәк кызларның уңганлыгы ,булганлыгы сыналган. Шуңа күрә яшь кызлар бер генә өмәдән дә калмаска тырышканнар.

Авылларда каз өмәсе гөрли
Юл буена канат сипкәннәр.
Канат өсләренә баса-баса
Кызлар каз өмәсенә бароалар
Әллә нинди генә сәер чак бу
Үзе моңсу ,үзе күңелле.
Каз гомере кире кайтмый торган
Яшьлек кебек кыска гомерле.

(Алып баручы артка чигенә.Шул вакыт бер төркем кызлар керә.Кулларында каз канатлары.)

**Бию. ”Каз канаты”.**

Гүзәл. Бүген бездә каз өмәсе
Каз өмәсе бүген бездә,
Каз йолкырга килгән кызлар
Уңыш юлдаш булсын сезгә.

Алинә. Көз көннәре бигрәк ямьле
Өмәгә килгән кызлар.
Матур булсын каз өмәсе
Тырышып эшлик кызлар.

Инзилә. Каурый сибәм су юлына
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күсәтеп

Бәйрәм итеп калыгыз.

Бии-бии сылу кызлар

Чыңлый чулпы төймәсе,

Борынгыдан килгән йола

Татарның каз өмәсе.

Айсылу. Ал да итәрбез әле

Гөл дә итәрбез әле.

Бергәләшеп бәлештән

Авыз итәрбез әле.

Инзилә.Әйдәгез кызлар.әйдәгез.Әти казларның эшен бетерде.Эш бездән генә тора.

(Утыралар,каз йолкалар) (Слайд)

Алинә.И, кызлар, карагыз әле.миңа бигрәк симез.зур каз эләкте бит.

Инзилә. Әйе, быел бигрәк унды шул казлар ,өй рәтеннән каз. Иртәгә Гөлсем әбиләргә барам..

Алинә . Кызлар дим ,әллә мин әйтәм, үзебез җырлый торган җырларны җырларны җырлыйкмы эш җиңел эшләнер иде.

**Җыр ."Күгәрчен гөрлидер. "**

Әби. Бигрәк матур җырлыйсыз инде балалар.Казларым да бик чиста булган,ярый әле өмәгә сезне чакырганмын.Әйдәгез кызлар мин казларның эчен алыйм ,ә сез өйне тәртипкә китерегез.

(Кызлар өй җыештыралар.)

Алинә. Егетләр киләме соң, Инзилә?

Инзилә. Киләләр, егетләр килмәгәч каз өмәсе була мени ул.Өйне җыештырдык,инде үзебезне тәртипкә китерик.Егетләр килеп җитәрләр алар.

(Егетләр шаулашкан тавыш ишетелә)

Рушан. Карагыз әле,егетләр Инзиләләрдә каз өмәсе , әйдәгезбарабыз.

Әйдәгез.әйдә.

Ислам.Нигә кертмисез кызлар?

Алинә. Бусага ялын җәлләмә

Сиңа киңәш һәм үгет.

Кызлар йөзен күрим дисәң

Акча түләп кер егет.

Гүзәл. Егет сиңа ни кирәк?

Малайлар.

Миңа симез каз кирәк.

Тагын матур кыз кирәк.

Кызлар. Каз казанга төшмәгән

Егет үзе пешмәгән.

Рушан . Ишек ача белмиләр,
Торабыз инде өшеп.
Ишек ялын күтәреп
Китәрбез әле кайтып.

Гүзәл.Кертик инде, я үпкәләп кайтып китәрләр.

(Егетләр керә. Кызлар белән исәнләшәләр)

Инзилә.Дусларым, бер биеп алыйк әле.

**"Шома бас"татар халык көенә.**

Рушан. Әйдәгез, "йөзек салыш" уенын уйныйбыз. (Җәзага җыр,такмаза,шигырь сөйләү.)

Әби. Балалар ,минем кесәдә төенчегем бар.Әбиләр кесәсе буш булмый ул. Мин сезгә мәкаль,табышмак әйтәм сез җавап бирерсез.

(Һәр балага мәкаль,табышмак әйтү). Рәхмәт сезгә ,балалар мин бүген сезнең белән рәхәтләнеп ял иттем. Яшь чакларыма кайттым. И, онытып та торам ләбаса, коймагым кабаргандыр , мичкә ягып җибәрим. Ә, сез балалар суга барып килегез.Самавыр куеп җибәрермен, бергәләп чәй эчәрбез.

**Бию. “ Чишмә юлында”**

Әби. Каз канатлары сибәбез
сез барасы юлларга,
Каз өмәсе бәйрәмнәрен
Бергә үткәрергә язсын
Киләсе елларга да.

**Җыр “Яшә син , Туган илем”**

## Кушымта 2

## Шушы яктан, шушы туфрактан без

**Максат:** Туган ягыбызны ярату, зурлау, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү; балаларның логик фикерләү сәләтен, хәтерен, диалогик сөйләм телен үстерү. Авылыбызның нәрсә белән данлыклы булуы турындагы мәгълүматларын арттыру.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, физик үсеш, социаль-коммуникатив, сәнгати үсеш.

Туган авыл турында слайд.

Сәхнә артыннан җирле шагыйребез Рәим Гобәйнең туган авылыбызга багышланган шигыре укыла( салмак көй куела).

Балалар бәйрәмчә киенеп чыгалар.

Балалар чыга (салмак көй).

Инзилә: Син тәуге кат баскан җирем,
Кояшлы таңым минем .
Иң шатлыклы булган җирем,
Көегем даным минем.

Айсылу:Комазан матурлыгына
Таң калам,сокланам мин.
Чөнки анын туфрагына
Тәпи баскан бала мин.

**Жыр: Туган авыл.**

Айрат чыга, карана карана сөйли: - Эх,.. нинди матур минем Көек-Комазаным, мин бик бәхетле... монда туганга.

Алинә:Миндә бик бәхетле, Айрат! Әби-бабаларыбызга рәхмәт. Шушы сокланып туймаслык тугае, челтерәп аккан чишмәләре, камышлы сазлыгы, балыклы күлләре,шаулап торган урманнары булган җирне сайлаганга.

Алмаз белән Айгөл керә:

Алмаз: Ә куе әрәмәләр белән уратылган елгалары, иркен басулары, кырлары турында ни әйтерсең Айгөл?

Айгөл:Әнә шундый булганга инде, Көек-Комазан җирен бернинди төбәккә дә тиңләрлек түгел.

Алмаз:Менә шушындый матурлыкны бөтен дөнья күреп таң калсын иде...

Бергә:Әйдәгез ТНВ каналын чакырабыз.

"Туган Җир" тапшыруыннан видео өзек

(Машина килгән тавыш ишетелә, балалар каршы алырга көтеп йөриләр.” Киләләр”, “киләләр” дигән тавышлар.)

Сәхнәгә "Туган җир" тапшыруының журналистлары һәм оператор (башлангыч класс укучылары) чыгалар.

Язилә: Исәнмесез, Көек - Ерыкса авыл җирлеге халкы, бүген төшереләчәк "Туган җир" тапшыруы Көек- Ерыкса авыл җирлегенең эш сөючән халкына, табигатенә багышлана.

Авыл турында слайд курсәтелә

Авыл халкы чыга: төрле милләт вәкилләре булып киенгән балалар.

Инзилә: -Әнә авылыбызның аксакалы да килә.

Ислам: - Кая, үзем каршы алыйм әле.

Аксакал (Илһам хәзрәт) - Әссаләме галәйкүм хөрмәтле кунаклар, авылдашлар. Менә мин дә "Туган җир" тапшыруы журналистлары килүен ишетеп килдем әле.

Фәнис: -Вәгаләйкүм әссәлам. Үзегезнең авыл җирлегендә эшләнгән матур эшләрегез, эшчән халкыгыз турында әйтеп китмәссезме?

Аксакал: - Халкыбыз  бик тырыш, тату. Безнең Көек--Ерыкса авыл җирлеге куп милләтле җирлек.Анда татарлар, руслар, марилар бер гаилә кебек бергәләп эшлиләр, дус-тату яшиләр. Әйдәгез әле башкаларның да уй - фикерләрен тыңлап карыйк.

1нче бала: юлларыбыз ремонтланды.

2 нче бала- Тиздән авылыбызда яңа пункт төзеләчәк.

3 нче бала -Әле бездә ветеренария пункты да булачак.

4 нче бала- Мәктәбебезгә капиталь ремонт үткәрелде.

5 нче бала - Бөек Җиңүнең 70 еллыгына яңа һәйкәлләр булдырылды.

6 нчы бала-чишмәләребез яңартылды.

Шәйхетдинов Фидаил Рафаилович керә.

Аксакал: Әнә җирлегебезнең  башлыгы Фидаил Рафаилович та кайтып җитте.

Исәнләшәләр.

Аксакал: - Менә энем ТНВ каналыннан туган ягыбызны төшерергә килгәннәр.

Фидаил Рафаилович: - Ишеттем, ишеттем. Шуңа күрә ашыгып кайттымда инде.Хөрмәтле аксакалыбыз каршы алгач бигрәктә яхшы булган.

Фәнис: - Бик күп эшләр башкаргансыз икән. Бу эшләрне башкарыр өчен финанс ярдәме дә кирәк бит. Сезгә андый ярдәмне кем күрсәтә соң?

Фидаил Рафаилович: -Әле болар эшебезнең бер өлеше генә. Районыбыз буенча да бик зур эшләр башкарыла. Болар өчен без барыбыз да районыбыз башлыгы Анатолий Петрович Ивановка зур рәхмәтебезне белдерәбез. Шулай ук авылдаш спонсорларыбызга - Гәрәев Зөфәр Мәлик улына, Гыймранов Салават Мәхмүт улына, Әһлиев Марат Мәсгуть улына, Вәрисов Илшат Рәис улына, Гыйльметдинов Айзат Мисбах улына, Бикташиров Миннәхмәт Нургали улына, Хәйруллина Мәдинә апаларга рәхмәтлебез. Ә хәзер әйдәгез әле гузәл ягыбызны урап узыйк (кереп китәләр)

Алмаз: Илһам бабай  курайда  уйнап күрсәт әле.

Аксакал:Бик рәхәтләнеп.(бабай курайда уйный)

Айгөл:Бигрәк матур инде,иеме Алмаз.

Алмаз:Минемдә курайда уйныйсым килә,мине дә өйрәт әле ак бабай?

Аксакал:Әйе балалар, туган җиреңне ,туган илеңне,туган ягыңның
моңын яратырга ,гореф-гадәтләрен онытмаска кирәк.Әйдәгез оланнар, курайда уйнарга өйрәтәм. (Чыгып китәләр)

Айрат: Авылыбызга багышланган шигырләр тормышыбызга ямь өсти.

Айсылу: Ә хәзер Ильмир Сәйфуллин башкаруында җыр тыңлап үтәрсез.

Җырлый Ильмир Сәйфуллин.

Алмаз: -Карале,Айгөл мин Акбабайның нәрсә әйтергә теләгәнен
аңлап бетермәдем әле.

Айгөл: Мин үзем дә шул турыда уйлап йөрим әле.

Алмаз:Моңа безнең генә баш җитми әле, әбидән сорарга кирәк.Киттек әйдә.

Айрат:-Их, шәп булды әле безгә “Туган Җир”нең килүе. Беләсеңме Инзилә: безнең төбәктә Малмыжка авылы да бар бит.Курсеннәр әле татарлар белән руслар ничек тату яшиләр.

Гүзәл:Әйе, дөрес әйтәсең алар бит үзләренең булганлыкларын узләренең җырларында әйтеп бирәләр.

**Жыр: Рус халык биюе”Кадриль”**

Рушан: (Кул чаба-чаба чыга.) Вәт булдырдылар ичмасам.

Бик вакытлы киләсез әле, әйдәгез әйдә, рәхим итегез.Буген бит бездә ярминкә... дип әйтугә гөжләп сатучылар килеп чыгалар Кая нәрсә сатасыз? дип сорый.Сату бара (кайсы носки ,җиләк-җимеш,мәтрүшкәләр,сөт-май һ.б.лар)

Җыр:Гүзәл туган ягыбыз.

(Комбайнерлар бер бәләкәй малай ияртеп, кулларын сөртә-сөртә чыгалар.)

Ислам:Көннәр генә ару торсын, жыеп алырбыз сау булсак икмәкне.

Шамил, Әмир, Хәлил чыгалар:

Мәрьям:Ничә бункер икмәк суктыгыз?

Зөлфинә:Унышларыгыз ничек?

Гүзәл: Ялларыгыз куңелле ,ашауларыгыз тәмле булсын.

Алина: Бүген район үзәгеннән авылдашыбыз Гөлнәзирә апа килгән.

Айсылу:Авылыбызнын горурлыгы,районыбызның мактанычы, Татарстаннын атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлнәзирә Талипова турында кемнәр генә белми.

Ильназ: Менә узе дә килеп җиткән.

Гөлнәзирә апа комбайнерларга : эшләрегез уң булсын ди.

Җыр:

Рушан:Гөлнәзирә апа ничек матур итеп җырлады.

Инзилә:Безнен авылның тәмле чишмә суларын эчеп үскән апа бит ул.Минем дә җырчы буласым килә.

Рушан:Сиңа тагын.Бөтен чишмә суын эчсәңдә Гөлнәзирә апа кебек җырлый алмыйсың син.Моның өчен талант кирәк,талант!

Көй куела Инзилә чыгып китә Рушан шигырь сөйли.

Шигырьне сөйләп бетергәч Инзилә яңадан чыга .

Инзилә:Рушан, ә син үскәч кем булырга хыялланасың?

Рушан:Мин агроном һөнәренә укып икмәкләрне үстерү нечкәлекләренә өйрәнергә телим.

Инзилә:Ә мин кош-кортларны,хайваннарны яратам.Мин аларны терелтер өчен ветеренар буласым килә.Безнең авылда ветеренар пункты төзелә диделәр бит.

Рушан:Без синең мәктәпкә укырга кереп ,аны тәмамлагач авыл хуҗалыгы институтына

китәрбез.

Инзилә:Әйе,аннары авылга эшкә кайтырбыз.

Рушан:Үзебезнен авылыбызның мәктәп сукмагын таптаган, бүгенге көндә район мәдәният йортын җитәкләүче авылдашыбыз Рамис Давытов Рамиловичне беләсеңме син?

Рушан:Беләм ә син анын матур итеп җырлаганын күргәнең бармы? Әйдәгез әле алкышлар белән үзен сәхнәгә чакырыйк.

Айрат:Сезнен өчен жырлый авылдашыбыз Рамис Давытов Рамилевич.

ТНВ каналы кешеләре керә .

Фәнис:Бигрәк күркәм як икән бу Көек- Ерыкса авылы җирлеге.Ә кешеләре нинди уңган булган .Кайда тәрбиялиләр мондый кешеләрне.

Айрат:Авылыбызнын нәкъ уртасында ике мәһабәт зур бина тора.Берсе балалар бакчасы,икенчесе Көек-Ерыкса урта мәктәбе .Әйдәгез шуларга юл тотыйк(чыгып китәләр)

**Бию: Татар халык бию е”Сөлге чигәм”**

Язилә:Бу күркәм балаларның тәрбияче апаларына сүз бирик әле.

**Жырлый: Илира Варисова.**

Рушан:Хөрмәтле хәбәрчеләребез ошадымы безнен Көек-Ерыкса җирлеге?

Язилә:Ошады бигрәк тә гүзәл икән сезнең яклар.

Фәнис:Юкка гына Л.Н.Толстой Италиядә,Неопольдэ яшәгенче мин Мамадышта яшәр идем дип әйтмәгән икән.

Рушан:Димәк бездән уңай фикерләр белән китәсез?

Фәнис: Бөтен Татарстанга күрсәтәбез әле без сезнең Мамадыш төбәген.Көек-Ерыкса авылын барысыда белеп бетерми бит.Бигрәк күркәм яклар.

Язилә:Туган жир тапшыруында сезнен төбәкнен һәммә кешесенен Мамадыш -туган йортым дип әйтерлеге бар икән.

Рушан:Хөрмәтле ТНВ хезмәткәрләре күп милләтле Татарстан жирлеге кебек безнен Көек-Комазан җирлеге дә төрле милләтәргә бай. Мари халкынын ничек яшәвен аларның биюләреннән күрерсез. Рәхим итегез.

**Бию: Мари халык бию е.**

**Жыр:Һәрвакыт булсын кояш.**

## Кушымта 3

## Туган ягым — яшел бишек

**Максат:** табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү; балаларның логик фикерләү сәләтләрен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; туган ягыбыз табигате турында белемнәрен тирәнәйтү; үз төбәгенең патриоты булу омтылышы уяту.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш.

**Җиһазлау.** Кош тавышлары язылган һәм татар халык көе белән аудиоязма; ел фасыллары, чишмә күренешләренә, урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә слайдлар; экран, LCD проектор; буклет өчен әзер өлгеләр.

**Алдан эшләнгән эшләр.** Шигырьләр өйрәнү, туган як табигате турында альбомнар карау.

**Эшчәнлек барышы.** Туган як, туган төбәк – халыкның бишеге ул. Кешенең бөтен тормышы, гомере туган як белән бәйле.

Син тәүге кат баскан җирем,
Кояшлы таңым минем .
Иң шатлыклы булган җирем,
Көегем даным минем.
Комазан матурлыгына
Таң калам,сокланам мин.
Чөнки анын туфрагына
Тәпи баскан бала мин.

Бу матур шигырь юлларыннан аңлагансыздыр инде, балалар: бүген без сезнең белән туган як табигате турында сөйләшербез. Табигать, һәр ел фасылы, аның һәр мизгеле матур, бары тик ул матурлыкны күрә генә белергә кирәк. Хәзер мин сезгә табышмак әйтәм, игътибар белән тыңлагыз: “Үзе чаба да чаба, койрыгы күренми”. (Елга.)

Бик дөрес, бу елга, ә елга нәрсәдән башлана соң, балалар?(Чишмәдән.)

Элек-электән кешеләр суны чишмәләрдән эчкәннәр. Су ул — яшәү чыганагы. Безнең туган ягыбызда да саф сулы чишмәләр бик күп. Әйдәгез, туган ягыбызның кайбер чишмәләрен барлап искә төшереп үтик.

(Балалар слайдларда сурәтләнгән чишмәләрне танып атыйлар. Иң соңыннан тирә-ягы чүп-чар белән тулган чишмә күрсәтелә.)

Балалар, бу чишмәгә игътибар итегез әле. Сез ничек уйлыйсыз, ул үзен ничек хис итә? Тирә-ягы шундый пычрак чишмәнең суы нинди икән? Ул башка чишмәләр кебек челтерәми. Сез ничек уйлыйсыз, бу чишмә гел шундый пычрак булдымы икән? Балалар, табигатьне шулай пычратучы кешеләрне ничек атар идегез? Аларга нинди киңәш бирер идегез? Балалар, уйлап карыйк әле: чишмәгә ничек булышырга, аны ничек терелтергә соң? ( Тирә-ягын чистартырга, чәчәкләр утыртырга, ягымлы сүзләр әйтергә, матур җырлар җырларга.)

Бик дөрес әйттегез! Без, бергәләшеп, сез әйткәннәрнең барысын да эшләп китәрбез, ләкин бит, тагын башка әдәпсез кешеләр чүп-чар калдырып, чишмәне пычратып китәргә мөмкин. Башкалар да үзләрен табигатьтә тәртипле тотсыннар өчен нишләргә кирәк икән? (Чүп-чар калдырмагыз! – дигән рәсемнәр ясарга.) Бик дөрес, балалар, мин дә сезнең белән килешәм.

Без төрле мәкаль-әйтемнәр беләбез. Мәсәлән, “Саф һава — тәнгә дәва”, “Табигатне саклаган — үз яшәвен аклаган”, “Җир караганны ярата”- кебек мәкаль-әйтемнәрне, плакатка язып, чишмә янына куярга була.

Ә хәзер, ял итеп, уйнап алыйк. (Түгәрәктә татар халык көенә “Парыңны тап” уены башкарыла.)

Без һәр елны, карлар эреп җирләр ачылгач, барыбыз да бердәм булып, яраткан авылыбыз Көек-Ерыксаны кар астыннан чыккан чүпләрдән чистартабыз. Нинди матур безнең туган ягыбыз! Аның тирә-ягында урманнар бик күп. Табигать кочагында булганда, без бөтен мәшәкатьләребезне онытабыз. Туган ягыбызның матурлыгына хозурланып, тын гына урман тавышын, кошларның сихри моңнарын тыңлыйбыз. (Аудиоязмада кошлар тавышы яңгырый.)

Туган ягыбызның кошлары турында белемнәрегез тирән, аларга карата тагын да игътибарлырак булыйк. Без аларны кайгыртсак, алар да туган ягыбыз табигатен саклауда безгә ярдәм итәрләр.

Әйдәгез, белемнәребезне тикшерү масатыннан, кагыйдәләрне искә төшереп, бергәләшеп уйнап алабыз. (Уен — “Кем җитезрәк”. Слайдта рәсемнәр күрсәтелә.)

Булдырдыгыз, балалар. Әгәр дә без табигатьне өйрәнмәсәк, андагы үсемлек һәм җәнлекләр дөньясын белмәсәк, чәчәк һәм агачлар үстермәсәк, җир анабызның гүзәлллеген сакламасак, ул безне гафу итмәс. Әгәр дә без туган ягыбызның табигате өчен изге эшләр генә кылсак, җир анабыз безне онытмас. Җиребез, суыбыз, һавабыз безнең яхшы эшләребезгә бары тик яхшылык белән җавап кайтарыр.

Хәзер сезне өстәлләр янына чакырам. Әйдәгез бергәләп ”Без табигать сакчылары” исемле буклетлар ясыйк. (Тын көй яңгырый, балалар буклетлар ясыйлар.)

Балалар, бу буклетларны, өйләрегезгә алып кайтып, әти-әниләрегезгә, дусларыгызга күрсәтегез һәм табигатьне яратырга, сакларга кирәклеген аңлатыгыз.

Балалар, бүгенге эшчәнлегебездән сез нинди кызыклы яңалаклар алдыгыз?

Көтелгән җаваплар: Туган ягыбыз чишмәләре белән таныштык, аларның кызыклы исемнәрен белдек.

- Чишмәләрне чистартып торырга кирәклегенә төшендек.

- Кошлар турында күп нәрсәләр белдек.

- Кошларны кайгыртырга һәм аларны сакларга кирәкләген аңладык.

- Урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыттык.

- Кызыклы буклетлар ясадык.

- Туган ягыбыз табигатен сакларга кирәклегенә инандык.

- Балалар, бүген сез барыгыз да бик актив булдыгыз. Туган ягыбыз турындагы белемнәрегезнең бай һәм ныклы икәнлеген күрсәттегез. (Алинә  Резеда Вәлиеваның “ Туган илем” шигырен сөйли)

Туган илем — басу, кырлар,

Урманнар, яшел юллар.

Инешләрем, чишмәләрем,

Туганнар, якын дуслар.

Шушы җирләрдә үтәләр

Балачак елларыбыз.

Шушы чакларны, олыгайгач,

Сагынып искә алырбыз.



**КУШЫМТА 4**

## Минем туган авылым

**Максат:** Балаларда туган якка карата кызыксыну, ярату хисләре тәрбияләү, туган авыл һәм табигате турында белемнәрен арттыру, туган авылыңның исемен белүләренә ирешү.Балаларда туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү, туган як белән горурлану хисләре уяту, авылның күренекле шәхесләре, авыл тарихы белән таныштыру; патриотик хисләр уяту.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш.

**Методик алымнар:** әңгәмә, сораулар. уен, мактау, җыр тыңлау, слайд күрсәтү.

**Җиһазлау:** “Туган авыл” җыры (Г.Тукай сүзләре), проектр, төзү материаллары, авыл рәсемнәре, хикәя төзү өчен схема.

**Алдан эшләнгән эшләр:** авыл буйлап экскурсияләр, әңгәмәләр үткәрү, җырлар, шигырьләр уку, күренекле шәхесләр белән танышу.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче: Хәерле көн, балалар. Әйдәгез әле бер – беребезгә карап, елмаеп алыйк әле – кәефләребез күтәрелсен.

Тәрбияче: Балалар, тыңлагыз әле, нинди матур көй ишетелә!

(Г.Тукайның “Туган авыл” җыры яңгырый)

- Сез бу җыр турында нәрсә әйтә аласыз?

( Бу “Туган авыл” җыры. Бу җыр Г.Тукай сүзләренә язылган)

Ә сез үзегезнең авылыгыз турында нәрсә әйтә аласыз?

1 бала сөйли: Минем туган авылым – Көек-Ерыкса. Авылым бик матур. Анда наратлык тавы бар. Җәй көне тауда  матур итеп кошлар сайрый, гөмбәләр үсә.

2 бала сөйли: Авыл башында бик матур умарталык бар. Өйләре матур, юллары тигез.

3 бала сөйли: Ул тау итәгенә урнашкан. Болында күлләр күп. Җәй көне без әти белән балык тотарга барабыз.

4 бала сөйли: Авыл уртасында һәйкәл бар. 9 май бәйрәмендә без анда барып шигырьләр сөйләдек. Анда мәктәп урнашкан. Мәктәптә экскурсиядә булдык.

5 бала сөйли: Авыл уртасыннан Ерыкса елгасы ага. Елгада балыклар бар.  Суда бобрлар  яши.

Тәрбияче: Балалар, безнең туган авылыбыз бик матур . Күреп торам, сез туган авылыгызны яратасыз. Сезгә авылда бик рәхәт. Ләкин авылда гел рәхәт кенә булып тормый икән. Кайчан безгә авылда бик рәхәт түгел? – уйлап карагыз әле. Авылның тискәре якларын әйтеп китик әле.

яңгыр яугач авылда пычрак була;аның юллары асвальт түгел;авылда эш күп;
авылда көтү көтәргә кирәк;урамда автобуслар йөрми;кибетләр күп түгел;больница юк, һ.б.

Тәрбияче: Сезнең урындык асларыгызда рәсемнәр бар. Бу рәсемнәрдә авылның яхшы һәм начар яклары күрсәтелгән. Хәзер сез рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнен әйтеп тактадагы кояш астына урнаштырырсыз.Авылда матур, саф һава, төрле чәчәкләр үсә, күбәләкләр оча – елмайган кояш астына куям;яңгыр яугач, юллар пычрак була – боек кояш астына куям;иртән әтәч кычкырып йокыдан уята – күңелле була;кич урамда утлар аз яна, һ.б.

Тәрбияче: Балалар, әйтегез әле сезнең үскәч , авылда яшисегез киләме, әллә шәһәрдәме? Ни өчен?(Балалар җавабы тыңлана.)

Тәрбияче: Әйдәгез әле менә бу битләрдәге биремнәрне эшлик әле.

Монда нәрсәләр сурәтләнгән? (Слайд күрсәтелә)(Транспорт төрләре.)

Нинди транспорт төрләре?(Авыл хуҗалыгы транспортлары.Җәмәгать транспортлары.Йөк транспортлары.)

Тәрбияче: Хәзер бер сызык белән бу транспорт төрләренең күбрәк кайда очратып булуын билгеләгез – шәһәрдәме әллә авылдамы?

(Балалар эшлиләр. Дөреслеген слайдка карап тикшерәләр)

Балалар, дөрес эшләдегезме, тикшерегез әле. Барыгыз да дөрес эшләдегезме?

Ә менә монда төзү материаллары. Хәзер кечкенәләр авыл урамы, ә зурлар шәһәр урамы (өйләр) төзерләр.

Балалар төзиләр.

Кечкенәләрнең авыл урамы төзелде. Сез өйләр төзү өчен нинди төзү материаллары кулландыгыз? (кирпич, кубик, өчпочмак) Сез бүген нәрсәләр эшләдегез? Нәрсәләр эшләргә өйрәндегез?

Сез бүген миңа бик тә ошадыгыз. Менә бу смайликлар кебек гел елмаеп торыгыз, шат күңелле булыгыз дип, мин сезгә смайликлар бүләк итәм.

Тәрбияче: Балалар, шәһәрдә йортлар нинди? (биек, зур, кирпичтән төзелгән) Син нинди өй төзедең?Ә синең өй нинди төзү материалларыннан төзелгән?Бик дөрес. Һәр авылны читләргә танытучы, шул авылда туып – үскән шәхесләр була. Алар кемнәр булырга мөмкин? (композиторлар, җырчылар, язучылар, биючеләр, төзүчеләр, һ.б.)

Безнең авылда да бар андый шәхесләр. Әйдәгез аларны искә төшереп китик.

Әйе, мондый кешеләр авылның патриотлары. Алар үзләренең туган авылларын, авыл кешеләрен бик яраталар, авылга кайтып йөриләр. Авылдашлары белән горурланалар, кулларыннан килгәнчә ярдәм итеп яшиләр.

Йомгаклау. Балалар, сезгә бүгенге эшчәнлектә нәрсәләр ошады?

Сез бүген бик актив булдыгыз, мин сезгә дә смайликлар әзерләдем.

"Гүзәл туган ягыбыз" җыры белән тәгәллибез.

**Кушымта 6**

## Авылым урамы

**(Уртанчылар төркемендә ябыштыру дәресе)**

**Максат**: Йорт рәсемен дөрес фигуралардан ябыштырырга өйрәтү,үз авылыбызның матурлыгын күрү, соклану, аны баету хисләре тәрбияләү, милли бизәкләрне таный, кисә, куллана белү сәләтләрен камилләштерү; ябыштыру, рәсем, музыка дәресләре арасында бәйләнеш булдыру.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш.

**Җиһазлар:**Авыл урамы рәсеме, магнитофон язмасында "Авылым урамнары" җыры; татар халкының чәчәк үрнәкләре, бизәлгән өй күренеше, кайчы, төсле кәгазьләр, клей, альбом бите.

**Эшчәнлек барышы:**

Исәнләшү. (Кунаклар белән исәнләшү) Магнитофоннан җыр тыңлау "Туган авыл"

**1.Әңгәмә.**

- Балалар, уйлап карагыз әле, җыр нәрсә турында
- Авыл турында турында
- Ә безнең туган авылыбызның исеме ничек? Хәзер һәрберебез үзебез яшәгән урамны күз алдына китерик (балалар күзләрен йомалар).
- Ни өчен матур безнең урамнар
- Йортлары зур, матур. Төрлечә бизәлгән.

- Безнең йортлар нәрсәдән салынган?

- Агачтан, таштан салынганнары да бар!

2.**Картина буенча эшләү.**

**-** Балалар, игътибар белән бу картинага карагыз әле. Аның йортларына игътибар итик. Алар нинди?

- Биек, матур, төрле төсләргә буялган

- Авылда йортлар күпме?

- Күп, тезелеп торалар. Урам булып утырганнар

- Әйе, берсеннән берсе матур йортлар,бер-бер артлы тезелеп, урам барлыкка китерәлә.

- Ә хәзер бу рәсемгә игътибар итик. Күңел нуры, нәфис зәвыгы, җитез кулларның осталыгы әнә ничек гөл итеп куйган бу йорты. Кешеләр бу йортны бизәүдә нинди бизәкләр кулланганнар? (Татар милли бизәкләре: лалә, кыңгырау, сырлы яфрак ) Бездә үзебез ябыштырачак йортны шул бизәкләр белән бизәрбез, балалар.

**3.Бизәлгән йорт рәсеме бунча эшләү.**

- Ә хәзер бу рәсемгә игътибар итик. Күңел нуры, нәфис зәвыгы, җитез кулларның осталыгы әнә ничек гөл итеп куйган бу йорты. Кешеләр бу йортны бизәүдә нинди бизәкләр кулланганнар? (Татар милли бизәкләре: лалә, кыңгырау, сырлы яфрак ) Бездә үзебез ябыштырачак йортны шул бизәкләр белән бизәрбез, балалар.

**4.Эшне аңлату.**

а) Өйнең нигезен-кара тасманы-альбом битенең иң астына урталыкка  ябыштыру

б) Башта-йортны, аннары түбә өлешен ябыштыру

в) Ишек һәм тәрәзәләрне ябыштыру.

г) Таныш милли бизәкләр белән өйнең кайбер өлешләрен бизәү. (Алдан киселгән милли бизәкләр белән балалар йортның үзләре теләгән өлешләрен бизиләр)

**5. Мөстәкыйль эш**.( булдырмаганнарга булышу

**6.Анализ уен формасында үтә.**

- Балалар, карагыз әле, шул кадәр күп йортлар.Алар барысы бергә нәрсә барлыкка китерә.

- Матур урам.

- Ә без нинди матур авыл урамы уртасында калдык! Сез бу йортларның кайсында яшәр идегез? (балалар үзләренә ошаган йортларны күрсәтәләр, бизәкләре турында сөйлиләр.

- Йортларга капка аша керәләр, шулай бит, балалар? Бездә хәзер сезнең белән “капкалы” уенын уйныйбыз. (Уен “татар халык бию көенә” башкарыла.)

Уен барышы

Уен башланганчы бер бизәкнең исеме атала. “Ачык авыз” булып калган  бала  шул аталган бизәкне алдан әзерләнгән бизәкләр арасыннан табып  күрсәтә

- Ә хәзер Инзилә үзләренең урамы турында шигырь сөйләп күрсәтер. Тыңлыйк әле, балалар. (Инзилә “Безнең урам” дигән шигырь сөйли)

- Рәхмәт сезгә, кадерле балалар. Шундый осталарыбыз булганда, безнең милли сәнгатебез мәңге сүнмәс, сүрелмәс.Сез үсеп җиткәч, безнең туган авылыбыз тагын да матуррак булыр, һәрчак  чәчәк атып торыр.

**Кушымта  7**

## Убыриянең сихри аланында

**(зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә балалар  иртәсе )**

**Максат.** Балаларның урман һәм андагы үсемлекләр,агачлар,куаклар,дару үләннәре,бөҗәкләр,җәнлекләр турындагы белемнәрен гомумиләштерү һәм күзаллауларын киңәйтү.Аларга карата сак караш тәрбияләү.Урманда үз-үзеңне ничек тоту кирәклеген балалардан сөйләтү.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, физик  үсеш, социаль-коммуникатив, сәнгати үсеш.

Мәрьям.Дусларым ,җыелыштыгызмы?

Айрат. Әйе,барыбыз да килдек.

Айгөл.Кәрзиннәр алдыгызмы?Бигрәк матур кәрзиннәрегез.Әйдәгез,киттек.(әниләре рөхсәт бирүләре турында сөйләшеп алалар)

Илназ.Әнием озак тормагыз диде.

Әмир. Ә миңа урманда гел бергә йөрергә куштылар.

Хәлил.Әнием кәрзиннәрегез җиләкләр белән тулсын дип теләп калды.

**Җыр: ” По малину в лес пойдём.”**

Зөлфинә. Менә җырлый-җырлый килеп тә җиттек. Әйдәгез, кызлар, урман белән исәнләшик.

Бергә: Исәнме, урман!

Шамил. Их, урманның һавсы нинди саф. Рәхәтләнеп иркен итеп сулыйсын.

Айсылу. Тыңлагыз әле, кошлар ничек матур итеп сайрыйлар.

Алмаз. Ә чәчәкләрдән, җиләкләрдән хуш ис бөркелә.

Ислам. Дусларым, мин бераз ардым әле. Сусатты да. Әйдәгез әле, каен җиләге эзләп карыйк.

Гүзәл.Кызлар ,килегез әле

Менә каен җиләге.

Бик тәмле ул ,бал гына

Авызыңа ал гына.

Шифалы су эчкәндәй

Сусавыгыз басылыр,

Күңелегез ачылыр.

(ашап караганнан соң)

Рушан.Сусауны тиз баса икән бу,чыннан да.Су эзләп йөрисе юк икән урманда.

Алмаз.Аның яфрагы да шифалы әле.Аз гына парда тотып,ярага(җәрәхәткә) япсаң,төзәлгәнен сизми дә каласың.Әйдәгез,кызлар, сак кына яфракларын да җыйыйк.Тамыры белән йолкый күрмәгез.

Алинә.Юк,юк,без сак кына(жиләк җыялар,бер тартмага яфрагын җыялар).

Инзилә.Ә мин кура җиләге таптым.Килегез монда.

Кура җиләген менә

Дару дисәң дә ярый.

«Кызыл доктор » дип аңа

Исем бирсәң дә ярый.

Суык тисә вареньесын

Чәйгә салып эчәсе.

(кура җиләге җыялар )

Алина. (читкәрәк китеп) Җимешләрен күр әле син,

Сабак буйлап тезелеп төшкән.

Без киләсен көткән кебек

Барысы да изелеп пешкән.

(өзеп кабыйм дигәндз ,аның янына 1 бала йөгереп килә.)

Гүзәл. Нишлисең син,Алина?

Бу бит бүре җиләге

Аны ашап бер малай

Шундый каты чирләде,

Ярый әле үлмәде.

Кызлар, яхшылап карагыз,бүре җиләге агулы җиләк.Аны бутамагыз!

Айрат. Кызлар,карагыз,балан да өлгергән.Бик яратам мин балан бәлешен.

Айсылу.Минем әни дә аны бик тәмле пешерә.

Әминә. Йөткерсәм дә,карлыксам

Әни миңа кич-иртә

Бераз гына бал кушып

Балан суын эчертә.

(балан җыялар,җырлыйлар)

-Әй ,балан,балан,блан

Балан баланлаганда

Баланнарга рәхәт була

Яңгыр тамгалаганда.

Баланнарны җыябыз

Какларын да коябыз

Тәмле итеп кайнатабыз,

Бәлешен яратабыз.

(җырлап бетергәч,елый-елый Куян керә.)

Куян. Ой,ой,ой!

Илгиз. Нигә елыйсың,куянкай?

Куян . Чабып йөргәндә очлы чыбыкка басып ягымны канаттым.Ой,ой,ой-би-ик авырта аягым.

Алинә. Елама,Кункай,без сиңа ярдәм итәрбез.Киселсә дә,канаса да иң әйбәт дару бака яфрагы.Әйдәгез ,дусларым ,тиз генә эзләп табыйк әле шуны.

Ислам. Менә мин таптым .(кайчы белән генә кисеп ала,юа,куянның аягын бәйли)

Куян. Рәхмәт сезгә,дусларым.(сөенеченнән җырлап җибәрә).

Бака,бакаяфрагы

Аякны дәвлады.

Юл буенда сез аны

Күрсәгез таптамагыз.

Аяк кабарса юлда

Аласың да ябасың

Шуннан шифа табасың

Торасың да чабасың.

(чыршы артында Аюның елаган тавышы ишетелә)

Илназ. Нинди тавыш анда? Кем бар икән?(Аю чыга)

Рушан. Нәрсә булды камыт аяк?

Аю. Күп итеп бал ашадым,тамак кипкәч салкын су эчтем,шуннн чирләдем,тамагым бик авырта, у-у-у.

Гүзәл. Хәзер безгә кирәк инде

Мәтрүшкәнең сарысы.

Хәлил. Ул нәрсәгә ярый соң?

Әмир. Бик күп төрле авыруга

Шифасы бар аның да

Тамакны да дәвалый ул

Эчәк авыруларын да.

Айгөл. Менә сиңа ,Аюкай, сары мәтрүшкә,кайнатып,тамагыңны чайкарсың.(Аю рәхмәт әйтеп китеп бара.)

Балалар игътибарларын себеркегә атланып чабучы дару үләннәренә юнәлтәләр.

Айрат. Нәрсә бу,гомеремдә беренче күрүем.Үзе оча,үзе чаба.

Инзилә. Ромашка түгелме соң бу?

Шамил. Ромашка,ромашка

Кая болай чабасың (ашыгасың) ?

Ромашка.Ашыкмый хәл юк.Соры колакка салкын тигән,шуны дәваларга барам.Убыр әбекәй очыртып җибәрде.

Балалар. Бар ,бар,тизрәк бул,соңга кала күрмә.

(Бака яфрагы битлеге кигән бала керә).

Алина. Ә син ,бака яфрагы,кая барасың?

Бака яфрагы. Тиенкәйнең күзенә арпа чыккан ,шуны дәваларга барам.

(Энҗе чәчәк керә).

Мәрьям . Энҗе чәчәк,энҗе чәчәк?Ә син кая чабасың?

Энҗе чәчәк.Гафу итегез,Төлкебикәнең нервылары какшаган,шуны тергезергә барам.

Айгөл. Кызлар,кызык бит әле бу,ә? Убыр әбекәй ниләр эшләп ята икән анда үзенең патшалыгында?

Алмаз. Әйдәгез,барып карыйк.(китәләр)

Убыр «Мәтрүшкәләр “не җырлап утыра.

Убыр.Менә,кунаклар килә икән.

Балалар. Исәнме ,Убыр әбекәй.

Убыр.Исәнмесез, балакайларым!Убыр түгел мин хәзер,дуктыр(доктор).

Рушан. Доктор булгач,бигрәк яшәргәнсең син,әбекәй.

Убыр. И,балалар,яшәрүен яшәрмәдем инде анысы.Төрле явызлыклар эшләмим хәзер,балакайларым.

Изге эшкә керештем бит,
Барысы белән дуслаштым.
Шифаханә дә ачтым
Мунчада да чабынам
Үләннәр дә ягынам.

Әйдәгез әле,утырышыгыз,арыгансыздыр,сусагансыздыр,тамакларыгыз да ачкандыр.Мич бәрәңгесе тәгәрәткән идем учакта.Йөрәккә бик файдалы бит ул ,ашагыз әле.Аннан тузганак яфрагыннан салат ясаган идем.Салаты белән ашагыз әле,анысы да бик файдалы.

(сыйлананалар). Шифалы чәйләр белән

Сыйлыйм әле ,мин сезне
Сусаганны да баса
Арганны да бетерә
Кәефләрне күтәрә
Җырлыйсы килеп китә
Биисе килеп китә.

Балалар.Чыннан да , бигрәк тә тәмле булды бу  чәй,җырлыйсы да, биисе дә килеп китте.

Убыр.Әйдәгез әле , бер күңел ачып алыйк.Күптәннән биегән дә, җырлгн да юк. Бизнес белән шөгыльләнгәч,биергә вкыт калмый икән.(“Карлыган” җырын  биеп җырлыйлар)Рәхмәт ,балакайларым,бигрәк булдырасыз икән.

Гүзәл. Әбекәй,киштәләрегез бик бай,сыгылып тора.

Убыр.Минем янга бик күп авырулар килә.Менә шулар өчен шифалы дару үләннәре  җыеп әзерлим мин.

Айсылу. Без дә бакчада дару үләннәренең  шифасы турында өйрәнәбез.

Убыр.Ягез әле,сынап карыйм үзегезне.Таныйсызмы икән,чынлап сөйлисезме икән?Менә монысы  ни икән?

Әмир. Бу-гөлҗимеш.Без аны салкын тимәсен дип,гел эчеп торабыз.

Убыр. Ә монысы?

Айрат. Бу –карлыган.Аның яфракларын җыеп киптердек,төнәтмә -чәйне  кыш буе рәхәтләнеп эчтек.

Убыр. Я инде,син әйт.

Алинә. Монысы сары мәтрүшкә. Эч авыртканда,салкын тигәндә файдалы.

Убыр.Монысы нәрсә икән?

Хәлил.Барыбызга таныш, бу-ромашка.Аның белән тамак чайкыйбыз.

Шамил. Монысы әрем.Күрше әбинең ашказаны авырткач,әни аңа әремне кайнатып эчертте.

Ислам.Бу- кычыткан.Аның согы,тамыры,яфраклары да бик файдалы.Аны ашка да салалар,салатын да ясыйлар.Мунчада төнәтмәсе белән коеналар,чәчне чайкыйлар.

Убыр.Мунча дигәннән,сезнең киләсен белгән күк ,мунча яктым бит әле мин,онытып торам.Кая тиз генә мунча хәстәрен  күрим әле.Сез мунчада чабынырга яратасызмы соң?

Балалар. Әйе,бик яратабыз.Тик безгә әниләребез озак тормаска куштылар.

Убыр. Бер дә борчылмагыз,мин сезне үзем озатып куярмын.Әйдәгез,мунчага.Шәпме балалар,мунча.Ягез әле ятыгыз,шифалы себеркеләр белән чабыйм әле үзегезне.

-Сине каен себеркесе белән (файдасы әйтелә).

-Сине имән себеркесе белән.

-Кил әле,юкә себеркесе дә бик файдалы.Кытыгыгыз киләме әллә?Чыршы белән нарат себеркесе тиреләрне йомшарта,тирене яхшы сулата. Ягез әле,чәчләрегезне кычыткан суы

белән чайкыйк,чәч төпләрегез ныгысын,кавыкламасын,чәчләрегез ялтырап торсын,тиз үссен.Яхшылып сөртенегез дә, чыгарсыз.(балалар зур сөлгеләргә төренеп , берәм-берәм чыгалар.

Убыр.Җинел пар белән.

Балалар.Рхмәт,әбекәй ,мунча хөрмәтенә.

Убыр.Шифалы чэйлэр эчегез дэ шушы "Шүрәле сукмагыннан" үтәрсез(массажлы юл,чикләвекләр,ташлар,күркәләр һ.б.)

**Җыр : ("Кара каш, кара күз " көенә).**

Мунчага барган идек
Эссе пар салган идек
Пар хәлебезне алды
Тәнгә шифасы калды.

Их,мунчасы ,мунчасы,
Хуш исләр аңкып тора.
Убыр чапты ,их эссе,
Шәп икән себеркесе.

Үлән чәйләре эчтек
Ылыс ваннасы кердек
Мунча шифалы икәнен
Тагын бер тапкыр күрдек.

Убырия.Карагыз әле ,балалар,нинди тау соң бу?Балалар.Тау түгел ул,кырмыска оясы.

Убырия.Беләсез икән,балалар,сезне сынар өчен генә әйткән идем.

Балалар. Алар бик файдалы.Минем әнием күрше апа белән ел саен кырмыска оясына кул-аякларын дәваларга йөриләр.

Убырия.Әллә без дә куеп карыйбызмы? Кырмыска ояларын туздырырга ярамый,алар-урман санитарлары. Ә хәзер ял итеп алыйк. Уеннар "Исеннән таны", "Тәменнән таны",Кайсы азыкта нинди витамин бар".

Убырия.Рәхмәт сезгә,балалар.Мине сөендердегез.Бик күп беләсез икән."Нәни докторлар"икән бит сез.(күчтәнәчләр бирә,себеркесенә утыртып очыртып алып кайтып куя.)

Урманга сез дә килеп китегез
Доктор әбине сез дә күрерсез.
Урман бик юмарт,кунак булырсыз
Саулык-байлык ул,аны саклагыз.

## Кушымта 8

# Аваз салды дөньяга балам-багалмам минем

(Мәктәпкә әзерлек төркемендә бәйрәм иртәсе)

**М а к с а т :** Балаларда татар халкының гореф-гадәтләренәдатар халык авыз иҗатына ихтирам, хөрмәт тәрбияләү, аларны өйрәтү.

Халкыбызның җырларын, биюләрен, шигырьләрен сәнгатьле итеп башкара алу сәләтләрен үстерү.

Халык педагогикасы нигезендә кешелеклелек, шәфкатьлелек, әдәплелек хисләре тәрбияләү, анага булган олы мәхәббәт хисләре тирәнәйтү.

**И н т е г р а л ь  б е л е м  б и р ү  ө л к ә л ә р е :** сөйләм үсеше, танып белү, физик үсеш, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш.

**Җ и һ а з л а р** : Авыл өе күренеше (түрдә өстәл, бишек эленгән ,бала юындыру өчен табак, курчак, эскәмия, көянтә, чиләкләр.)

**Алып баручы**. Быелгы ел-яшьләр елы.Яшьләр елы дигәч,күз алдына никахлашу, бәби туу,беренче шатлыклар килә.Безнең күбебез бу тойгылар-. ны кичергән кешеләр.Әйдәгез бер генә мизгелгә үзебез дә бу бәйрәмнең шаһиты булып алыйк.

Өй күренеше. Алда эскәмия,бала-чагалар эскәмиядә утыралар.

Рузия. Безнең әни бәби алып кайтырга китте.Кыз бирерләрме икән,малай бирерләрме икән.

Ирек. Әти малай булсын дип әйтә,әби кыз кирәк ди.

Резидә. Исеме ничек була соң инде бәбинең?

Рузия. Мин беләм.

Люзия. Әйт әле.кем була?

Рузия. Кыз булса ,Зифа кушабыз.

Зәринә. Бигрәк матур була икән исеме.

Ирек. Зифа-чибәр,сылу,зиннәтле була икән,әбием шулай диде.

Зәринә. Ә минем исемем Зәринә-алтын бизәкләрне аңлата.

Резидә. Мин әле шундый матур исем беләм-Камил.Әниең малай алып -кайтса, Камил дип кушарсыз.

Динар. Ярар, кем булса да ярый, урамыбызда уйнарга иптәшләр генә артсын.

Кызлар. Кыз булсын,кыз булсын.

Малайлар. Юк.малай булсын,безнең урамда кызлар болай да күп.

Кызлар. Кызлар,кызлар дигән буласыз,кызлар алар йолдызлар, ә малайлар-чүплектәге калайлар.

Малайлар. Хәдичә,Хәдичә бер самовар чәй эчә.

Кызлар. Әвәли,шәвәли көлдән ипи әвәли.

Малайлар. Әллүкәй.бәллүкәй,

Хәдичә һаман бәләкәй,

Бармак белән тисәң дә

Әнкәсенә әләкләй.

Кызлар. Көлмә кешедән, авызың өшегән.

Айзәрә чыга. Энемне бишектә тирбәтә тирбәтә уенга соңга калдыммы әллә дусларым?

Балалар. Юк әле,юк,сине генә көтәбез.

Айзәрә. Нәрсәле уйныйк соң?

Балалар.Әйдәгез"сукыр тәкәле"уйныйбыз.

Ирек.Мин "сукыр тәкә"

Резидә.Юк.мин.
Айзәрә.Кая,үзем саныйм әле,кем чыга шул була.

Җепсез орчык, Чәүкә чыпчык, Кара балчык Син кал бу чык!

Зәринә.син буласың сукыр тәкә. ("Сукыр тәкәле"уйнлар)

Гөлия.Әйдәгез җырлап -биеп тә алыйк инде.

Татар халык җыры "Зәңгәр чиләк"

Әби.Әйдәгез .балакайларым бик озак уйнадыгыз инде ,ашау вакытын да оныттыгыз ахрысы. Балалар өйләренә таралышалар

Зилә.Сөенче,сөенче!Әминә әби.сөенче бар бит әле.Кыз оныгыгыз туган.

Әби.И аллага шөкер рәхмәт балакаем. Менә сиңа сөенчегә йомырка. Бала йомырка кебек тәгәрәп үссен.

Зилә.Рәхмәт.Мин әле Мәдинә апаларга да сөенче алырга барам.

Әби.Бар,балам .бар.Сәфәр аенда туды,алла бирса,бәхетле,михербанлы,шәфкатьле бала булыр .сау-сәламәт булсын инде.

Рузия.Әби.әкият сөйлә әле. | Әби.И, балакайларым,бәби кайтуга бишекләрне,чүпрәкләрне барлармын д и г ә н идем.

Ирек.Сөйлә инде.әби. Әби.Сөйлим инде алайса.Борын-борын заманда яшәгән ди ,бер әби белән бер бабай.Аларның булган ди,кызлары.Исеме -Сөйләмә булган ди.Көннәрдән беркөнне шул кыз...Исеме ничек дидем әле ул кызның? Балалар.Сөйләмә.

Әби.Сөйләмә дигәч,сөйләмим инде алайса. Балалар.Әби син бит алдап кына утырасың.Сөйлә инде. Әби.Ярар.тагын берне сөйлим инде.Бер әби белән бер бабай яшәгәннәр. Аларның булган ди әтәчләре .Ул әтәч көн дә менгән ди киртәгә,калганын сөйләрмен иртәгә.

(Әби үз эше белән китә.)

Балалар.Әби дә остарды.

Ирек.Беләсеңме әби нәрсә пешергән?

Рузия.Пәрәмәч.

Ирек.Ике күзең тәгәрмәч.

Рузия.Әнә,үрти инде хәзер.

Ирек.Ярар.бүтән үртәмәм.Сөт диген әле.

Рузия, Сөт. ,

Ирек.Борыныңны сөрт. Рузия.Әнә бит ул.(Йөгереп кереп китәләр.)

**Алып баручы**. Дөньяга яңа кеше туды.Ул үзенә бәхетле киләчәк даулап тәүге авазын салды.Бу турыда ишеткән ьәр кеше эченнән генә"Мул ризыгың.киң бәхетең миһербаның-шәфкатең иман-тәүфигың белән кил нарасый"-дип теләде.

Бәби туу-элек-электән гаиләдә бик тә олы шатлык саналган.Бу уңайдан халкыбызда бик матур гореф-гадәтләр формалашкан:бәби кабул итү,исем кушу,коендыру,ягымлы сүзләр.изге теләкләр әйтү.

Ана бишек янында.

Алтын - алтын,алтыным
Минем йөрәк ялкыным
Уяндыңмы бәбкәм,күз нурым
Кояш булып балкырмын.

Үсә-үсә зур була, кояш кебек сөйкемле ,үзе сүзгә җор була.

Ана. Әнкәй әллә Зифаны коендырып алыйк микән?

Әби.Әйе шул, кызым.Җылы сулар да бар.(Әби су алып керә.) (Әби белән ана баланы юындыралар.)

Салкын су,чиста су
Баламның битләрен ю,
Баламның күзләрен ю.
Битләре алсулансын,
Күзләре ялкынлансын,
Куллары таза булсын. (Коендыралар)

Суы сарыксын.үзе калыксын,
Тигез канатлы булсын,
Озын гомерле булсын
Игелекле,шәфкатьле булсын
Бәхетледәүфийклы булсын.

(Ана баланы төрә,бишеккә сала.Бишек җыры җырлый.)

Шигырьләр. 1 Бүген шатлык күңелдә
Бәйрәм һәммәбезгә дә,
Бәбиебез бар безнең
Сөйлим әле сезгә дә.

Әбием дә сөенә, этием дә сөенә,
Әниемне әйткән дә юк,
Җырлый бишек көенә.

2.Бәби кайткан йортка
Шатлык кайта.
Сөю.сөелү кайта,нур кайта.
Бәби кайткан йортка
Мең мәшәкать белән
Күкрәкләргә тулып җыр кайта.

3.Бәби кайтты бүген өйгә
Җыр туды яңа көйгә
Ризыклары мул булсын,
Килер җире киң булсын,
Дип теләде әби дә,
Дип теләде әни дә.
Кардәшләр дә котлады,
Изрәп бәби йоклады.

4. Яңа бәби алып кайтты
Әни базардан.
Күрше-күлән кереп тулды
Бәби карарга.
Кергәннәргә күрсәтәләр бары тәпиен,
" Юкса күз тидерәсез"-дип көлә әбием.
Ничек итсәм иттем әле.хәйләсен таптым
Кеше югында биләвен-чиштем дә бактым.
Шаккатмылы икән чынлап нәни аяк-кул,
Бәбиебез сокланырлык матур икән шул.

**Алып баручы**.Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган.Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле.җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан.Без моны татар халкының борынгы җыры Рәйхандагы

" Аклы ситса күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган,
Исеме матур,кемнәр куйган

Сине күреп кем туйган?” -дигән шигъри юлларында бик ачык күрәбез.

(Балалар парлашып чыгалар.)

"Чума үрдәк.чума каз" татар халык җыры.

Ана.Сезнең матур тавышыгызны ишетеп чыктык әле. Әби.Бигрәкләр дә матур җырлыйсыз инде.

Ана.Ә без яшь чакта бигрәк тә "Йөзек салыш"уенын яратып уйный идек.

Рузия.Без дә беләбез ул уенны.

Зилә.Әйдәгез уйныйбыз.мин йөзек салам.

("Йөзек салыш" уены. Җәзага 1 бала-этәч булып кычкыра, 2 бала-татарча бии,3 бала-җырлый."Күгәрчен гөрлидер" татар халык җыры, 4 бала-ягымлы сүзләр белән баланы йокыдан уята:

Тор,тор кызым, тор инде
Йокың туйгандыр инде.
Син яраткан курчакларың
Күптән торганнар инде.

5 бала - бәбине үчти-үчти иттерә:

Үчти-үчти үчтеки,
Үсте китте кечтеки.
Үсте-үсте зур булды,
Акыллы зирәк булды
һәркемгә кирәк булды.

Әби.Әбиләрнең кесәсе бер дә буш булмый инде ул. Менә бүген дә кесәмдә төенчегем бар. Әллә төенчек белән уйнап алабызмы? Әйдәгез әле, мәкальнең башы минем телемдә, ахыры төендә.Төенчек кемгә төшә , мәкальнең ахырын шул әйтә.

1.Әни суккан-авыртмый.

2.Дөньяда иң йомшак нәрсә- әни кулы.

3.Анаң кебек кешегә тел озайтма.

4.Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган әрәм булган.

5.Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,олыгайгач үзе дә игелек күрмәс.

Табышмаклар әйтә.

1 .Тап табышмак.табага ябышмак. (коймак)

2.Өр яңа савыт тишелеп беткән. (иләк)

3.Әйткәч беләсе килә,белгәч көләсе килә. (табышмак)

Әби.И,балакайларым,тагын бер җырлап күрсәтегез инде.

Жыр."Шома бас" татар халык жыры.

Ана.Барыгыз әле балалар, тәмле чишмә сулары алып кайтыгыз.Самавыр куеп чәй эчәрбез.

Бию. "Су юлында"татар халык көе. (Балалар су алып кайтала, ана чәй куярга кереп китә.)

Илзирә.Әйдәгез әле, чәй кайнаганчы бер җырлап әйләник әле.

Татар халык җыры "Талы.талы"

Ана. Әйдәгез, чәй кайнады,бергәләп чәй эчик әле.

Әби.Әйдәгез,әйдәгез арыгансыздыр да. (Кереп китәләр)

**Кушымта 9**

# Яңгыр боткасы

**(уртанчылар төркемендә бәйрәм иртәсе)**

**Тәрбия бурычлары:** халык авыз иҗаты нигезендә кешелеклелек, шәфкатьлелек, әдәплелек хисләре тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** халкыбызның җырларын, биюләрен, шигырьләрен сәнгатьле итеп башкара алу сәләтен үстерү .

**Белем бирү бурычы:** балаларга татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәтү.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш, физик үсеш.

Алып баручы. Безнең төрки бабаларыбыз онытыла барган изге бәйрәмнәре безнең көннәргә әйләнеп кайтты. Яңгырсыз,эссе җәй көннәрендә безнең әби-бабаларыбыз балалар белән бергәләп авыл халкыннан азык- төлек җыеп су буенда ботка пешергәннәр.Өлкәннәр яңгыр яудыруны үтенеп дога укыганнар.Балалар яңгырга,кояшка мөрәҗагать итеп шигъри әсәрләр башкарган, уеннар уйнаганнар.

Кич. Әби белән бабай капка төбендә утыралар.

Бабай. Карчык,быел яз да иртә килде инде,көннәр дә әйбәткә ошый,тик нигәдер яңгыр гына яумый.

Әби. Әйе, картым. Борынгылар кыш кар күп булса җәй яңгырлы булыр дигәннәр, быел кар да күп яуды инде югыйсә.

Бабай. И, карчык карале (һавага карап) , йолдызлар бик кечкенә күренә, яңгыр булыр ахрысы.

Әби.И,ул сынамышлары да туры килми башлады инде хәзер, тик менә яңгыры бик кирәк шул.

Бабай. Кирәк шул, карчык. Яңгыр яуса уҗымнар да тишелеп, матурланыр иде.Әнә агачлар да яфрак яра алмый утыра,бар табигать яңгыр көтә,яңгыр кирәк шул барыбызга да.

Ике малай кичке уеннан кайтып киләләр.

Әби. И, балакайларым көнозын уйныйсыз,уйнап туймыйсыз.

Алмаз. Әби, без уйнадык та, уйнадык, бер уен да калдырмадык.

Әби. Аргансыздыр инде кереп йоклагыз.

Рушан. Әби, әйдә бер әкият сөйлә дә инде, аннары кереп йоклыйбыз.

Әби. Яшәгән диәби белән бабай.Боларның булган ди ,әтәчләре. Әтәч көн саен менгән ди киртәгә.Әкиятнең калганын сөйләрмен иртәгә. Алмаз. Шаярасың бит син әби.

Рушан.И,әби шаяртма инде.

Алмаз. Бабай,син бик уйга батып утырасың. Нәрсә турында уйлыйсың?

Бабай. Менә әбиең белән сөйләшеп утыра идек әле, улым. Яңгырлар яумый бит. Без бала чакта , яңгырлар озак яумый торса ,яңгырны чакырып китерә идек..Әллә мин әйтәм, иртәгә бөтен авыл бала-чагасын җыеп чишмә янында яңгыр боткасы пешерик микән.

Алмаз. Әйе шул бабай, бер бәйрәм булыр иде.

Рушан. Рәхәтләнеп шаярырбыз.

Бабай. Сезгә шул шаярырга гына булсын инде.

Әби. Әйдәгез,балакайларым кереп йоклыйк,бик соң бит инде.

Балалар. Иртәгә яңгыр боткасы, иртәгә яңгыр боткасы! Ур-ра!

Балалар өйдән өйгә йөреп азык-төлек җыялар, авыл халкын яңгыр боткасына чакыралар.

Җырлап киләләр: Җырлыйк әле(2)

Ишетсеннәр, күрсеннәр

Яңгыртуйга җыелганнар

Бертуганнар дисеннәр.

Эх,күңел ачабыз

Яңгырны чакырабыз!

Балалар. Ярма,күкәй җыябыз

Сез дә бераз бирегез,

Тәмле ботка ашарга

Яңгыртуйга килегез.

Әби. И, балакайларым, изге ният белән йөрисез икән, бик яхшы. Изге хәбәрегез өчен авызыгызга бал  ягыйм (балаларга бал каптыра)

Балалар. Рәхмәт , әби озак яшә.

Икенче өйгә керәләр.

Ярма –күкәй җыябыз

Сездә бераз бирегез,

Тәмле ботка ашарга

Яңгыртуйга килегез.

Әби. Рәхмәт, бик яхшы булыр. Яңгыры да явар алла теләсә, хәерлә хәбәрегез өчен авызыгызга сары май  (май каптыра).

Балалар. Рәхмәт әби, рәхмәт.

( Балалар җырлап чишмә буена киләләр. Алар кулында чиләкләр,табак,казан,кулчатыр,ярма, күкәй, кәрзиннәр.)

Чишмә янында әби белән бабай:

-И, балакайларым, килеп җиттегезме? Менә бөтен авыл бала-чагасын җыйгансыз. Бик яхшы,ходай кушса яңгыры да явар,җилдә вакытында исәр, әйдәгез вакытны бушка уздырмыйк,малайлар учак ягарга чыбык-чабык җыйсын,башкалар ярма чистартсын.

Алинә белән Ислам. Әби,суны үзебез алып киләбез.

Бию “Су юлында”.

Әби. Кая ярмаларны чистартып бетердегезме әле?

Кызлар, хәзер әби, хәзер.

Җыр “Бәйрәм  җыры”.

Балалар. Менә әби,булды, чистартып бетердек.

Бабай казан аса, учак яга.

Әби. Рәхмәт балакайларым, хәзер ботканы пешерергә куябыз (казанга су, ярма, тоз сала).

Ботка пешкәнче, әллә мин әйтәм, уйнап-җырлап алыйк микән, күңеллерәк булыр иде.

Балалар. Әйе шул,әйдәгез әле.

Татар халык уены “Суда- суда”.

Илназ. Богыр-богыр ботка пешә

Уртасына ак май төшә

Яңгыр яу,яу,яу!

Бабай. Без яшь  чакта  “Түбәтәй”  уенын уйнарга ярата идек.

Балалар. Бабай, без дә беләбез ул уенны.Әйдәгез уйнап алыйк.

“Тубәтәй” уены. (Түбәтәй кем дә кала , шуңа җәза бирелә).

1. Татар халкының милли ризыклары?

2. Татар хатын-кызларының баш киеме ?

3.Татар  егетләренең баш киеме?

Әби. Яңгыр яумый да яумый. Балалар әйдәгез яңгырны чакырыйк әле.

Инзилә.	Яңгыр яу, яу, яу!

Бакчаларда алмагач

Корый яңгыр булмагач.

Бакчалардан ни файда

Алмалары булмагач.

Яңгыр яу, яу, яу!

Гүзәл.	Яңгыркаем яу, яу, яу!

Үләннәр дә бик үссен

Җиләк-җимешләр пешсен

Сыерларның сөтләре

Әз булмасын, күп булсын.

Хәлил. Яңгыр яу,яу, яу!

Сине көтә җир, җир

Безгә күмәч бир, бир!

Әби. Яңгыр безне ишетте ахрысы, җил дә исеп куйды.Әйдәгез бер биеп алыйк әле.

Татар халык көе “Зәлидә”.

Әби. Ә хәзер “Капкалы” уенын уйныйбыз.(Җәзага санамыш, табышмак, әкият).

Ислам. Әллә яңгырны җырлап чакырып карыйкмы? Бәлки ишетер безне.

Җыр “Яңгыр”.

Әби (кулчатырларны күреп). И, балакайларым , нинди хәл инде бу,үзегез яңгыр боткасына килгәнсез,үзегездә кулчатырлар.

Сәмирә. Әби,без кулчатырларны яңгыр яуганда кача-кача биербез дип алып килдек.

Әби. И, нинди яңгыр , болыты да күренми, җиле дә ялганчы гына булды ахрысы.

Инзилә. Ник әби,син бит яңгырны чакыргач килә дигән идең? Инде җырлап та, биеп тә чакырып карадык , ник яумый соң ул яңгыр?

( Бабай әкрен генә су алып балаларга сибә.)

Балалар. Яңгыр ява!

Рушан. Бабай, нишлисең син?

Бабай. Яңгыр яудырам! Менә шушы була инде ул яңгыр боткасы!

( Балалар бабайдан күреп су сибешәләр.)

Балалар. Ур-ра! Яңгыр ява!

Кулчатырлар белән бию.

Әби. Аллага шөкер,яңгыр да яуды,ботка да пеште, әйдәгез ашап алыйк.

Балалар. Тәмле микән боткасы

Авыз итәек әле,

Матур җәйне каршылап

Бәйрәм итәек әле!

(Бабай казанны уртага алып куя.Иң элек әби белән бабай авыз итә).

Әби. И, бигрәкләрдә тәмле,тозы да чыккан, ашагыз балалар.

Балалар. Бигрәк тәмле яңгыр боткасы

Бабай. Телләрегезне йота күрмәгез.

Балалар. Эшләгәндә йөрәгеү җилкенсен,

Ашаганда колагың селкенсен.

Бабай. Тырыштыгыз балалар,яңгыр да яудырдыгыз, ботканы да сыпырттыгыз.

Әби. Шифалы яңгырлар булсын, вакытында явып торсын. Еллар имин, тормышларыбыз мул булсын, балалар гел шат булсын!

**Кушымта 10**

## Сабантуй бәйрәме

**Максат:** балаларда милли үзаң, милләткә һәм аның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт тәрбияләү.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, физик үсеш, социаль-коммуникатив, сәнгати үсеш.

Сабан туе буласы көнне мәйданчык бизәлә: төрле төстәге шарлар, чиккән сөлгеләр, кулъяулыклар эленә.Татар музыкасы яңгырый.

**Алып баручы.** –Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар, хәерле көн! Без бүген татар халкының олы бәйрәме- Сабантуена җыелдык. Сабантуй - ул хезмәт бәйрәме, Сабантуй - ул дуслык бәйрәме, Сабантуй - ул һәркемнең көтеп алган изге бәйрәме. Котлы булсын Сабан туйлары! Кадерле балалар! Балалар бакчасында эшләүче барлык тәрбиячеләр, апаларыгыз исеменнән сезгә бәхетле балачак, ныклы сәламәтлек телим. Алдагы көннәрегез дә бүгенге кебек ямьле, күңелле булсын. Өстәлләребездә ризыклар мул булсын!

Сабан туе, хезмәт туе,

Шатлык һәм бәхет туе

Бәйрәм итик көн буе!

Котлы булсын, балалар,

Ямьле Сабан туйлары!

**Рушан.**Шатлыклар - күңелебездә.

Ал кояш күгебездә.

Килегез, дуслар,кунакка

Сабантуй бүген бездә.

**Алмаз.**Күңелле Сабантуйлары

Бүген бәйрәм, зур бәйрәм.

Матур җырлар җырлый-җырлый

Уйныйбыз әйлән –бәйлән.

(Шүрәле белән Су анасы килә.)

**Су анасы**: Исәнмесез, балалар!Хәлләрегез ничек?

**Шүрәле**: Исәнмесез,балалар! Без үтеп барганда сезнең матур итеп шигырь сөйләгәнегезне, җырларыгызны ишеттек.

**Су анасы:** Безнең сезгә кунакка киләсебез килде. Ә бүген сездә нинди бәйрәм?

**Балалар:** Сабантуй бәйрәме. Рәхим итегез!

**Шүрәле:**Бигрәк озын кулларым,

Күзләрем йөреп тора.

Килеш -килбәтемне күргәч,

Көләсең килеп тора.

Мин Шүрәле, Шүрәле,

Чакыргач килдем әле.

Онытып үпкәләрне,

Көлдереп алыйм әле.

**Балалар җырлый.**Ачуланган, турсайган

Шүрәлене күр әле.

Онытып килгән инде,

Былтыргы үпкәләрне.

Әй, Шүрәле, Шүрәле,

Безнең яңга кил әле.

Син яхшы бит,

Син әйбәт бит,

Бергәләп уйныйк әле.

“Сабан туе” җыры яңгырый.(М.Садри шигыре. Халык көе.)

**Ислам.**Җилферди чиккән сөлгеләр,

Бүләкләр күбебездә!

Көрәшик тә, узышыйк та,

Сабантуй бүген бездә!

**Гүзәл.**Сабан туенда уеннар

Төрле була, күп була.

Уеннарсыз Сабан туе

Булмаган да күк була.

“**Таяк тартышу” уены.**

**Алинә.**Кемнәр өлгер, кем җитез-

Минем янга килегез.

Әйдә, карыйк ярышып-

Капчык киеп чабышып.

“ **Капчык киеп йөгерү” уены.**

**Алып баручы.**Ерак китә алмыйлар

Капчыктагы балалар.

Аптырагач траклап та,

Мүкәләп тә карыйлар.

(Көлә-көлә кул чабалар.)

**Илназ.** (Чүлмәк ватарга таяк тотып чыга.)

Мактана дип уйламагыз,

Мин урынлы мактанам.

Чөнки менә бу чүлмәкне

Күрмичә дә ваталам.

“**Чүлмәк вату” уены.**

**Хәлил.**Батыр калу өчен әле

Миңа бераз иртәрәк.

Тик шулай да Сабан туен

Үзем башлап җибәрәм.    -Я кем белән көрәшәбез? (Кулында сөлге.)

**Әмир.**Сабан туе, сабан туе!

Шундый кызык, күңелле.

Ник чыкмаска көрәшергә

Мин соң егет түгелме?

**Шамил.**Егылсам да исем китми,

Булыр еккан чаклар да.

Бүген бәйрәм – Сабан туе

Безнең туганякларда.

“**Көрәш” башлана.**

**Алып баручы.**(Күкәй салган кашыклар тоткан.)

Кашык кабып йөгерәм дип,

Мактанырга ашыкма.

Ә син менә йөгереп бак

Күкәй салып кашыкка.

“**Күкәй салган кашыкны авызга кабып йөгерү” уены.**

(2 бала узышалар, башкалар көч биреп торалар.)

**Алып баручы.**Шунда бер җиргә тагын

Стан куйганнар кагып,

Шул станга ике малай

Утырганнар атланып.

“ **Капчык белән бәрешү” уены.**

**Айсылу.**Кулга тотканнар асып,

Салам тутырган капчык,

Капчык белән чиратлашып,

Бәрешәләр “шап” та “шоп”.

**Зөлфинә.**Берсе бик дәү- фил хәтле,

Берсе безнең Хәлил хәтле.

Хәлил хәтлесе фил хәтлесен

Бәрде екты бик каты.

( Мәйдан гүли.)

**Алып баручы.**Колга башына кем менә? (Колга башында - уенчык әтәч.)

“**Колга башына менү” уены.**

**Инзилә.** Менә сиңа сулы чиләк
Көянтә ал иңеңә.
Йөгер тизрәк, иң алдан кил
Егыла гына күрмә. **( су ташу )**

**Мәрьям**.Р .Миңнуллинның “Сабантуйда” шигырен сөйли.

**Алып баручы.**Уйнап тора музыка,

Зур мәйдан шау-гөр килә.

Җырлыйлар да, бииләр дә,

Төрлесе төрле көйгә.

**Айрат.**Алсу гөлләргә күмелгән

Безнең тирә-як.

Гүзәл гөлләрдән дә гүзәл

Безнең балачак.

“ Бәхетле балачак” җыры башкарыла.

**Айгөл.**Тыпыр-тыпыр тыпырдашып

Бергә басаек әле;

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп

Күңел ачаек әле.

(Барысы бергә бииләр. )

**Илназ.**Без уйныйбыз, уйныйбыз,

Якты көннән туймыйбыз.

Сабан туе гөрләп торсын,

Биибез дә җырлыйбыз.

“Чат-чат” җыры бию белән башкарыла. (Р. Гатауллин музыкасы, халык сүзләре.)

**Алина.**Шатланып уйныйк та, көлик без.

Күмәкләп җырлыйк та , биик без.

Әнкәйдәй кадерләп үстергән илкәйгә

“Зур рәхмәт! Зур рәхмәт!”-диик без.

“ Мин яратам сине, Татарстан” җыры башкарыла.(Р.Рәкыйпов шигыре. Р. Андреев көе.)

Уеннар, ярышлар дәвам итә, бүләкләр тапшырыла.



## Кулланылган әдәбият.


1.Әхмәтҗанова М.Бала күңелен рәнҗетмик.//Мәгариф, 1996. №3

2.Веракса Н.Е. Балалар бакчасында гомумбелем бирү программасы.Мәскәү,2014

3.Закирова К.В. Иң матур сүз. Казан. 2000.

4.Закирова К.В.,Борһанова Р.А. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы Казан. 2000.

5.Закирова К.В.,Кадырова Р.А. Әдәп төбе- матур гадәт. Казан. 1998

6.Закирова К.В.,Кадырова Р.А.Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе.Казан. 2013

7.Закирова К.В.,Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. Казан.2011

8.Закирова К.В,,Кадырова Р.А.,НизамовР.А. Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе. Казан. 1999

9.Зарипова Ф. Бала бишеге-гомер ишеге. Яр Чаллы.

10.Зарипова З.М. Туган телдә сөйләшәбез.Казан “Фолиант”2012

11.Зиннурова Ф.М. Үзилемдә ,үз телемдә.Казан”Мәгариф”2009

12. Шәехова Р.К. «Региональная программа дошкольного образования», Казан. 2012

13.Хәзратова Ф.В. Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге.Казан. 2013

14. Хәзратова Ф.В. ,Шәрәфетдинова З.Г.,хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез.Казан 2013